***Рөстәм Зарипов***

# *ӘФЛИСУН ҖИЛЕ*

***Шигырьләр, хикәяләр***

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1:3
ББК 84(2Рос=Тат)-5:4
З-26

**Зарипов Р.З.**

Әфлисун җиле: шигырьләр, хикәяләр / Рөстәм Зарипов. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2008. — 95 б. — 1000 д. — ISBN 978-5-298-01710-7

Әлеге китапка авторның төрле елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре һәм хикәяләре тупланды.

УДК 821.512.145-1:3
ББК 84(2Рос=Тат)-5:4
ISBN 978-5-298-01710-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Зарипов Р.З., 2008

# Шигырьләр

## Бүре

Урманга карый дип гаеплиләр
Бүректәге бүре баласын.
Бәгырьсезләр мәңге аңлый алмый
Нарасыйның йөрәк ярасын.

Адәм исе сеңгән йонлач бүрек —
Җәнлек тунап теккән киемдер,
Бүре балакайга аның эче,
Кичерегез, җәннәт түгелдер...

Һәм бүреккә аны аучы салган,
Атып алгач газиз әнкәсен.
Бәйгә күнектереп, бәләкәйдән
Эткә әйләндерү максаты!

Урманга карый дип гаеплиләр
Бүректәге нәни бүрене.
Ә бит ул тумыштан ватанпәрвәр,
Шуңа илен барлый үрелеп...

## Ак килешә

Бурый буран, ишеп кар ява,
Җилләр якалаша-ялаша;
Ак корабка охшап ак калалар
Кыйбласын югалтып адаша...

Күмү тантанасы дәһшәтле,
Ак барханнар тузгып шуыша;
Сукмак җуйган киек, ышык эстәп,
Эскерт кәрванына елыша...

Ахры, дөнья тәмам саташа,
Ак ком шәкелендә су баса!
Бер үк мәлдә без ак чүл гизүче,
Ак океан кауме ләбаса?!

Ватаным, сиңа ак килешә,
Гүзәллегеңнән күз камаша.
Язың, көзең, җәең ямьле, беләм,
Кышың үзгә гүзәл, тамаша!

* * *

Инде менә күпме уйладым:
Таш яуса да, давыл кузгалса да,
Җилгә очмас төсле, яшәр сыман
Минем тузганактай хыялым.

## Ак болытлар йөзеп йөрер күктә...

Әйләнеп карама як-ягыңа,
Хыял-тауга күтәрелгән чакта.
Тотанаклы җисем эзлә күктә,
Казык йолдызга бак йә кояшка...

Борылып карама үткәненә,
Тавың түбәсенә ашмый торып.
Башың әйләнер дә ычкынырсың,
Тотып кала алмас ястык-болыт...

Үткәнеңне барла адым саен,
Югарыдан түбән төшкән заман.
Тау түбәсе кабат дәшәр өскә,
Ә үткел суырыр аска һаман...

Ак болытлар йөзеп калыр күктә,
Карлы тау түбәсе булыр ерак...
Шундагы саф салкынны сагынып,
Вакыт-вакыт үрсәләнер йөрәк...

## Империя

Карап торырга соклангыч:
Ирек кебек иркен зәңгәр киңлек...
Акчарлаклар оча. Гаҗәп, гаҗәп сусаклагыч...
Тик күмелеп калган төптә
Кайчандыр тау-таш ярган чишмәләр...
Сандугачсыз, талсыз һәм кояшсыз,
Исле су күләмен ишәйтәләр...

## Безне көтәләр...

Кешеләр көтү булган, ди, борын заман,
Як-якка бак, әле һични үзгәрмәгән.
Без — көтү, безне көттеләр һәм көтәләр,
Кешечә җәмгыять кору хыял һаман.

Рәчәй — колхоз. Эчендәге гөбернә дә,
Каласы да, саласы да колхоз инде.
Милиция, армия, уку йортлары,
Һәр берәмлек, һәр күзәнәк колхоз имди.

Язучылар колхозының үз рәисе,
Колхозчы бездә артист та, журналист та.
Сталин калдырган мирас — системадан,
Тайпыла алмабыз, ахры, бер карыш та.

Әтрәк-әләм каләм әһле яза чүп-чар,
Сәхнә тулды әтрәк-әләм җырчы илә.
Ат брачы дипломына кем ия, шул

Бөек халкыбызны каулый, сава, җигә...

Һәр рәис калыплый бары шундый «шәхес»,
Кушканны дәшми үтәүче мокыт-сәрхуш.
Мокытлыкка, сәрхушлеккә кем күнмәде,
Онга тартты системаның тегермәне...

«Берләшик!» — дип аваз салды милләтпәрвәр,
Сарык хәлдә берләшүдән ни мәгънә бар?
Матди, рухи мая зарур, ныклы бәдән,
Дәүләт тумас берләште дип этрәк-әләм.

Татарның затлы катламын барлыйк әле,
Аңа лаек урын бары югарыда.
Табып, арчып «әрлән балчык» кочагыннан
Күптән вакыт аны өскә чыгарырга.

Үз урынын тапса гына затлы катлам,
Кешечә яшәүгә таба хет бер атлам,
Кузгалырбыз. Ә әлегә хәлләрем яман.
Татар — көтү. Табынганы, димәк, чабан...

## Кырым

Әллә сихер, әллә тылсым, әллә ырым,
Җан да тарта, кан да тарта сиңа, Кырым;
Туганнар җирен ботлаган ятлар гына
Кунагыңа төксе тора, карый кырын...

Каралар коела икән безгә ятлар,
Кара йөрәкләрдән аша күккә корым;
Шифалы һаваңны иркен сулыйм дисәм,
Җыерыла, көек исен тоеп борын...

Тозлы диңгез сулары да алмый, ахры,
Караларга каткан күңелләрнең керен;
Әйдә ярар. Ә без сагынып килдек әле
Кардәшләрнең күңел нурын, матур җырын...

Диңгезкәеңнең исеме нигә «кара»,
Кара кайгыданмы кайнап ярга кага?
...Күктә — кояш... Татарларың күкрәгендә
Мәңге сүнмәс һәм сүрелмәс яра яна...

## Әни

Кайчак хөкем итә якын дуслар,
Сөйгән ярлар, җиде ятлар да.
Япа-ялгыз газиз әниең килә
Сине араларга, якларга.

Уңны-сулны тоймый чапты гомер,
Юлга алсу гөлләр сипкәннәр,
Җиңел икән тормыш йөге иңдә,
Син дип шундый йөрәк типкәндә.

Башны аска иеп торам әле,
Сары яфрак күмә каберен.

Яфрак өзелгәндә искәрәбез
Газиз әнкәйләрнең кадерен...

## Беренче кар

Беренче кар... Тагын ява беренче кар...
Нинди якты сезнең урам! Нинди ап-ак!
Тәрәзәңдә ут бар, яна яран гөле,
Эзләремдә җәйнең көле, сары яфрак...
Күзләремә туры карый алырсыңмы,
Шатлыгыңны сагышыңа авыштырып;
Мин тыңларга әзер синең һәр сүзеңне,
Йөрәгеңнең тибешенә чагыштырып...

## Халәт фасыллары

Мәхәббәт кабына, таң ата —
Бар дөнья ал нурга күмелә.
Һәм тургай йөрәгең күкләрдә
Җыр булып кояшка үрелә.
Хисләнә болытлар
Саф көмеш тавышка;
Кояшлы яңгырда
Адаша сагышлар.

Мәхәббәт яндыра, ал гөлләр
Җилләрдә очкындай сибелә;
Акчарлак йөрәгең ял таба
Шашынган дулкыннар иркендә...
И дәрья, айкама,
Бу кадәр чайкама
Ак җилкән канатлы
Шул нәни корабны...

Мәхәббәт сүрелә, йа Хода,
Канатлар әйләнгән күмергә,
Һәм язган яшәргә үрмәләп,
Очышны татыган күңелгә...
Каяндыр ерактан,
Биектән ургый моң.
Синме бу, сандугач?
Исәнме, әй, былбыл?..

## Солтанәхмәт

Солтанәхмәт, диләр, шатлык тоеп,
Кем төзегән күкне каеп, уеп;
Гүя мәрмәр атып торган фонтан,
Бер мизгелгә туктап калган оеп.

Солтанәхмәт тора нурлар чәчеп,
Айя-Суфияне күккә дәшеп;
Кеше рухы мәхәббәтне шулай
Бәян иткән, ташлар аша шашып.

Зәңгәр мәчет илә Алсу мәчет
Тора ярда икәү җитәкләшеп;
Китәр кебек алар диңгез өсләп,
Югалырлар төсле күккә ашып...

Аһ, Төркия, алсу гөлләр иле,
Сине назлый зәңгәр диңгез җиле.
Ташларыңны сыксаң, шул ике төс
Тамчы-тамчы янып тамар иде...

* * *

Күтәрелеп карадың да
Янымнан киттең узып.
Тукталып калдым да торам,
Атын туарган арба күк,
Ике кулымны сузып...
Ияреп китәр идем бик,
Куып җитәрмен кебек.
Җиткәч, каушап, сүз куша алмый
Узып китәрмен кебек...

* * *

Китеп барган чак та булды,
Кайтып киткән чак та;
Маңгай терәп баганага
Торган чак та чатта...

Уйлыйм, капылт кына әле
Тагын бер кителер;
Дөньяның чите ул чакта,
Мөгаен, кителер...

## Парадокс

Үз туганы белән кара дошман —
Бар милләтне берләштермәк булды.

Хатынына баш була белмәгән —
Президентлыкка дәгъвасын кылды.

Сыңар хулиганнан коты очкан —
Барча урысларга күсәк изи.

Рәтле гаилә дә кора алмаган —
Безгә, имеш, тәти дәүләт төзи...

Адәм рәтле нәселдән чыкмаган —
Затлылык хакында теш агарта.

Нәсихәт укый әхлаксыз... Надан,
Отканнарын сөйләп, җиңнән тарта...

## Туташ

Туташ хәтәр, күзләр камаша,
Бер күрүе хәйран тамаша.

Җидедән үргән камчыны селтәп,
Сыдырсаң да каеш күңеленә,
Тырналу да анда калдырмыйча,
Чажлап кына шуып үтәчәк...
Коелып төшә иде кайчан гына
Саксыз ымнан, әрсез караштан...
Хәзер хәтәр, күзләр камаша,
Яннан узып китә ләбаса!..

## Ишек шакыдылар...

Ишек шакыдылар көтмәгәндә,
Баштан төшеп китте түбәтәй.
Төксе караш ташлап түргә үтте
Тикшерүче, ике пүнәтәй.

Каян, нәрсә тартып чыгарырлар?
Башта төрле уйлар — чүмәкәй...
Әле генә бөркет иде йөрәк,
Инде пыр-пыр килгән чүрәкәй...

## Урман

Нинди ямьле кышкы урман!
Ак каеннар бигрәк якты.
Ак каендай якты көннәр
Кая акты, кая акты?

Нинди ямьле язгы урман!
Кар астыннан ага сулар.
Кар астыннан аккан судай
Сизелми дә уза еллар.

Нинди ямьле җәйге урман!
Җәйге урман тора моңнан.
Сандугачлар җырын тыңлап
Аткан таңнар, узган төннәр.

Көзге урман — алтын урман,
Очкынланып җилдә шаулый;
Урман түгел, безнең гомер
Дөрли-дөрли кайный шулай...

* * *

Җәйне — яшәү, кышны тыну, диләр;
Күңел күнми мондый шартлылыкка.
...Җылы якта безнең ватандашлар
Тилмерәләр кышкы яктылыкка...

* * *

Юк, яратмый идем, күрсәм җилдә
Сыгылуын зифа талларның;
Ул чак үзем ачы миләш идем,
Кырау сукты, мин дә балландым...

* * *

Кайчакларда сагыш ачыттыра,
Талый, борлыктыра күңелне.
«Хуш килдең!» — дип, ишек ачып тора,
Түрләренә әйдәп үлемне...

* * *

Беркем хәтерләми икебезнең
Зәңгәр күкне кыеп очканны!
Бер сызгырып куям ачы итеп,
Сискәндереп кунган кошларны...

## Майтап җиңгинең Халит абзый колагына ирештергәннәре

Синең суга бармау, миңа суга,
Зинһар, бүген генә барчы суга.
Ә мин, бәгърем, китәм кычытканга,
Чәүчәләк йөрәгем кычытканга.
Майтап, май тап, дисең, бәгърем Халит,
Син ир кеше, майны үзең хәл ит!
...Өстәлдә алма бар, аны алма,
Казанда салма бар, аны салма,
Юкса ач калырлар балалар, дип,
Кемгә — әрем, безгә бал алар, дим.
...Көзләр җитәр, кырда башак тулыр,
Картаербыз без дә, баш ак булыр;
Утын эзләп чыгып китәрбезме,
Йөрәк утын сарыф итәрбезме?
— Ботак кирәк! — дисәм, аңларсыңмы?
— Бот?! Ак! — диеп чыгып чапмассыңмы?..

## Төш

Мин төш күрәм, имеш ки, мин күк хадиме,
Җир язмышы сыйдырылган монитордан,
«Т» атлы төймәгә басып, һәр адымын
Татар милләтенең, имеш, карап торам.

Татар — тырыш, билен буып дуңгыз бага,
Тирес түгә, җир сукалый, күмер чаба;
Вакыты тар, хәтта милли бәйрәмен дә
Кайсы елны оештыра шыксыз көндә.

Гайрәт чигеп басам башка төймәләргә...
Мониторны карнаваллар биләп ала...
Политика... Экзотика... Эротика...
Мондый поэтикадан җан эреп китә...

Карап ятам хозурланып, хөҗерләнеп,
Кяфер кавемнең шаукымлы мәгыйшәтен;
«Мөселман... чечен... фәлән...» дип борчысалар,
«Тс-с, — мин әйтәм, — пожалысты,
не мешайте!»

Тәмле төшемне шул мәлдә бүлдерәләр,
Сүзне миңа бирелгәнен белдерәләр;
Депутатлар авыз ачып карап тора,

«Аһ, — мин әйтәм, — өн дә пука ярап тора...»

* * *

Имеш, матур чәчәк атсын өчен,
Бирсен өчен җимеш,
Кеше күңеленә бераз гына
Тирес керү тиеш...

* * *

Җитәкчене шуннан таныйм:
Басуга кереп китә дә
Үреләгел башакка;
Өзә, бөртекләрен саный,
Исни, куя ашап та...

* * *

Аргамактан туа тулпар,
Ишәктән ишәк инде.
Каулаучыңнан чамалыйсың
Үзеңнең кемлегеңне...

## СССР тарихы

Сөннәткә утыртылды тәре,
Анысы ярый әле.
Килеп чыкты чүкеч —
Булды бер эш.

Ә кисекне сап итеп,
Беркеттеләр айга.
Булып чыкты урак —
Тагын файда.
Эшче ир һәм крәстиән хатын,
Тотып шушыларны,
Коммунизмга дип
Җитмеш өч ел барды...

## Туган тел

Синдә сандугач һәм чишмә,
Синдә кыя, упкын, лачын һәм
Һәркемгә җитешле моң,
Телә — ела, телә — ачын!

Телә — елмай Җәлилләрдәй,
Йә Дәрдмәндтәй сагышлан,
Йә ян, дөрлә Тукай булып,
Халкыңа берек, багышлан.

Кайсы телне алып бакма,
Үткәнен һәм бүгенгесен —
Җир белән күк аермасы,
Калса калган бер-ике сүз...

Синең сүзләргә тутык юк!
Синең сүзләр — саф энҗеләр!
Ничә гасыр гомер кичеп,

Бүгенгедәй җемелдиләр.

Ә «Мин — бай!» дип, «Мин — гүзәл!» дип,
«Мин — бөек!» дип шапырмыйсың,
Каядыр китәсең дә күк,
Тик дәшмисең, чакырмыйсың.

Син китәсең, халкың кала,
Өсте бөтен, тамагы тук,
Бабалары зиратында
Дуңгыз йөри актарынып...

«И туган тел, и матур тел»,
Берүк ташлап китмә безне,
Сакла моңны, сакла рухны,
Сакла кешелегебезне...

## Һәйкәл

Нурлы Казанында мәңгегә
Муса зынҗырланган, дисәләр,
Ышанмагыз, андый һәйкәлне
Дуслар кормас, аны сөйсәләр.

Мондый һәйкәл тиеш калкырга,
Багышланса әгәр Җәлилгә,
Алман дигән илнең түрендә,
Моабит төрмәсе янында.

Һәр чын шагыйрь кыска гомерендә
Кабатлый үз халкы язмышын;
Тамчысына кадәр эчкән ул
Татарына төшкән каргышның.

«Яугир булган, ут вә су кичкән,
Әсир төшкән, башы чабылган,
Асыл исеменә ни гомер
Катлам-катлам яла ягылган...»

Әмма хаклык барыбер килә,
Ансыз кыен безнең халыкка;
Җәлил исеме дә беркөнне
Сүнмәс ялкын булып калыккан.

Уллы — милләтенә, ә милләт
Бер улына мөмкин охшарга;
Ул һәйкәлгә мин бик еш киләм,
Очрашу билгеләп дусларга.

Чәнечкеле зынҗырлар белән
Боргычланган мәзлум халкыма.
Казан йөрәгендә һәйкәл бар! —
Ул азатлык даулап талпына!..

## Җирсү

Зәңгәр күктә йөзә ак болыт,
Күзәтәләр шуны онытылып...
Кыр казлары китә тезелеп,
Озатып калалар өзелеп.

Ә төннәрен йолдыз атыла
Күккә багучылар хакына;
...Тән — Җирнеке, Рух ватаны — Күк,
Күкне җирси күңел һәр минут.

## Зыялыларыбыз

Милләтнең күкрәген изгән ташка басып,
Зыялылар акыл сата чиратлашып.

Берсе дәшә: татар халкы, уян инде!
Икенчесе: ул бит күптән куян инде...

Өченчесе: ул хөсетле, сатлык, имеш,
Тагын берсе: аңа юлдаш картлык, имеш...

Кайсы әйди: чеченнардан үрнәк алыйк!
Бәгъзеләре: яһүд төсле булып карыйк...

Ирененә су тидерми бер баласы —
Ята милләт, аһ, ничекләр тын аласы...

## Бу безнең ил түгел...

Паспортымны ачып укыйм —
Мин шушы илнеке.
Әмма ышанасы килми,
Килми, бетте-китте.

Тургайдай күккә чөелми,
Менми, очмый күңел;
Ә йөрәкнең һәр типкәне:
— Бу безнең ил түгел!

Бу илдә тиз төшерәләр
Муен тамырыңа.
Кемдер тез астыңа тибә,
Бөер, бавырыңа.

Бирешми яшәргә мөмкин,
Булмаса да җиңел,
Тик һәр күзәнәгең сизә,
Бу безнең ил түгел...

Телең, денеңнән яздыра
Һәр бирмеш көн монда.
Каян эзләргә ватанны,
Кайда безнең урда?..

## Исе китәр иде исәрнең

Исе китәр иде исәрнең,
Мин яратам, дисәм, мишәрне...
Истә: «первый» булып килде ул,
Кем ошамый, шуны сөрде ул.

«Алды» Минзәләне, Мөслимне,
«Бөкте» Мамадышны, Сарманны,
«Кәкрәйтте» Зәйне, Актанышны,
«Тотты» Кукмараны, Сабаны...

Исе китәр иде исәрнең,
Гаепләсәм әгәр мишәрне,
Гүзәл әкиятен Алишның,
Гамьле моңын Хәйдәр Бегичнең,

Имәнинең камил иманын,
Исхакыйның ихлас күңелен,
Акчураның алтын акылын,
Батыршаның мәгърур үлемен...

Еники иҗаты агышын,
Габдулла Рәхимкол тавышын,
Пакь өметен Хәсән Туфанның,
Шашкын рухын Һади Такташның...

Түрәләре кылган гамәлләр
Кузгатса да йөрәк давылын,
Алар күләгәсе генә тик
Каплый алмый мишәр кавемен!

## Мишә ярыннан йөгердек...

Мишә ярыннан йөгердек
Агымсуларга каршы.
Карлыгач кебек талпынды
Бәгъремнең кара кашы.

Мишә суы алып керде
Карурман түрләренә,
Башкаемны салыйм, бәгърем,
Күкрәгең үрләренә.

Мишә сулары башында
Карурман чишмәләре.
Бәгърем, суын болгатырсың,
Ярларын ишмә әле...

Чишмә буе ярларында
Былбыл кунар тал була.
Салкыны — ялкын, сулары
Яшь йөрәккә ял була.

Чишмә ярыннан йөгердек,
Агымсуларга уңай.
Бөтен дөнья нурга чумган,
Мин гашыйк булдым бугай.

Агымсулар алып төште
Ямь-яшел болыннарга.

Әйләник әле, дускаем,
Уралып толымнарга.
...Тәгәрик әле, дускаем,
Уралып толымнарга...

## Фоторәсем

Мәскәү журналында төсле рәсем —
Нәни малай дуңгыз сыртында.
Атланган да каулый йөрәксенеп,
Мәхлук алга ыргый мыркылдап.

Оча җайдак, тар күкрәге ачык,
Очлаеп тырпайган тезләре.
Кашлар дугай-дугай, борын почык,
Очкын чәчә кысык күзләре.

Эчә-тарта икән инде үзе,
Шәп сызгыра, ерак төкерә.
Туган теле белән ара өзек,
«Бөек» телдә хутлы сүгенә...

Сурәтнең астында тасвир кыска,
Эчтәлеге тоташ сагыш-моң.
Рәхмәт төшсен фотожурналистка,
Шәп каптырган халык язмышын.

«Улым» дип назлап килә дәшәсе,
Чулым халкы — төрки туганым.
Ахрысы, син һични төшенмисең
Үзең белән нәрсә булганын...

Нишләттеләр сине, кайсы дошман,
Ник чучкага менгән оланың?
Өс-башың алама, тәмам тузган,
Нигә битләреңне юмадың?

Кемнәр оныттырды бабаңнарның
Охшауларын мәгърур шоңкарга?
Иш булалмый синә каты борын,
Син чабарга тиеш тулпарда!

Башыңны күтәреп бак әле бер
Күктә янган якты йолдызга.
Исерексең, аңламыйсың, бәгырь,
Елышасың һаман дуңгызга...

Бер гөнаһсыз нарасый баланы
Эчүгә өйрәтү — җинаять.
Ул сабыйны алда ни көткәне
Аңлашыла торгандыр, шаять.

Себернең саф, садә халыклары
Сабыйлардан сабый иде ич!
«Өлкән туган», дуслык аныклавы,
Кружкада спирт сузды — эч.

Эчемлекнең җылытуын татып,
Табигать уллары шатланды.

Ансат эссе эстәп, яше-карты
Шул «шайтан суы»на капланды.

Беркатлы халыклар каян белсен
Зәһәр яшел елан мәкерен.
Үлем күләгәсе сиздермәстән
Калкып чыкты әкрен-әкрен...

Торба сузар, юллар салыр өчен,
Арчылган арадан җил барып,
Шаяргандай йөри, агачларны
Домино шикелле аударып.

Актарыла уңдырышлы катлам,
Себерә дә аны җил ала.
Һәм чигенә тайга атлам-атлам,
Урынында сары чүл кала...

Фаҗигаләр уртак, хәтта тәңгәл,
Тунап алгач затлы катламын,
Ком бураны булып күтәрелгән,
Чәчелгән, сибелгән татарым...

Игелек иле ул — Рәчәй, диеп,
Тагын кем ул, кайсы саташа?
Халыкларга кан-яшь, афәт, үлем
Китерүче ул бит ләбаса!

Күпме кавемнәрне атландырып,
Аргамакка түгел, дуңгызга,
Җитмеш өч ел ул бит «шатландырды»,
Алга! диеп, коммунизмга!

Эче ялган аның, тышы ялган,
Алдашудан авызы бушамый,
Кайсы әйдаманын гына алма,
Һәммәсе дә Иван Сусанин.

Мәскәү журналында төсле рәсем —
Нәни малай дуңгыз сыртында...
...Татарстанны да дуңгыз баса...
Колакларда тоташ мыркылдау...

## Юл чатында

Юл чатында таштан язу укып
Уйга калган татар егете;
Каян барса чәлпәрәмә килмәс
Шушы яшь егетнең өмете?

Сулга китсә, карак түрә көтә,
Егет булыр аңа олтырак,
Һәр бирмеш көн хәрам мал китерер,
Машинасы торыр елтырап.
(Кесәләрендә акча чылтырар,
Тик гомере үтәр калтырап...)

Туры китсә, кунар керфегенә
Олы, озын юллар «сөрмәсе»,

Сындырырга теләр армиясе,
«Кеше итмәк» булыр төрмәсе,
Сынауларны узып исән кайтса,
Барыбер көтмәс аны түр башы...

Кая барырга соң, кайсы якка,
Кай тарафка китеп абынсын?
Сарык булыр, бүре, бүре булып,
Сарык тиресеме ябынсын?

...Тик бер киңәш: нәсел — черемә,
энекәш,
Малга хирыслык та ялгыш ул;
Юнәлешне кыйбла якка сайла,
Иманыңны күкрәгеңдә сакла,
Күзләреңдә нуры балкысын!

## Хирург монологы

Кемнең генә бүксәсен ярсам да,
Гел бер үк нәрсәгә юлыктым;
Кеше карбыз түгел, бәхәсләшмим,
Һәм хакыйкатьтән дә курыкмыйм!

## Ирек мәйданы. 1991

Октябрьнең урталары иде,
Җыйналышып әллә кайлардан,
Татарстанга бәйсезлек даулап
Агылды кардәшләр мәйданга...

Якты уйлар. Изге хисләр белән
Мәйдан тулды, кызды, кайнады.
Кинәт әллә каян пәйда булды
Канлы империя байрагы...

Аны тотып яшь бер үсмер барды
Җанлы тере кыршау эчендә,
Милиция түше белән шулай
Каплый империя көчеген.

Көчек ләң-ләң өрә татарларга,
Авызыннан утлар төкерә,
«Рәхмәт, ипи ашатасыз, дими,
«Вы — фашисты!» диеп җикерә.

Аннан парламентны камадылар,
Әйтерсең Шаһгали чирүе.
Нурсыз-моңсыз күзле, тук чырайлы
«Хокук саклаучылар» өере...

Гавам арасына таратылган
Провакаторлар да тик ятмый,
Милициягә килеп бәрелеп,
Бугаз ертып милләтне «яклый».

Гамәлләре канун кысасында,
Шәрә йодрык белән сукмыйлар,

Махсус фәрманга таянып кына,
Резин таяк белән тукмыйлар.

Нәкъ дүрт йөз утыз тугыз ел элек,
Октябрьнең шушы көнендә,
Мәскәү вәхшиләре бире килеп,
Татар канын эчеп күбенгән.

Нәкъ дүрт йөз утыз тугыз ел буе
Ирек даулаганга, бүген дә
Татарларның Хәтер көнендә
Татар каны җиргә түгелә.

Халык экстремист булып чыкты,
Милиция, имеш, фәрештә...
Министр оялтты Фәүзияне,
Сабак бирде Марат, Фәндәскә.

Шаһгалимовмы соң, бер полковник,
Генерал чыгышын баетып,
Байтак йокымсар депутатларны
Татлы йокысыннан айнытты.

...Әйткән, имеш, карайөрәк Иван,
Шулай диеп халкын әйдәгән:
Мәскәү бөеклеге Казан җирен
Үзләштерү белән бәйләнгән.

Килгән явыз дошман, күргән, җиңгән,
Урам тулып аккан ал каннар.
Шәһитләрне төяп, Идел иңләп
Төшеп киткән ерак күп саллар...

Мәскәү журналында төсле рәсем
Күкрәгемдә давыл кубарды
Һәм искә төшерде Пешләдәге
Аксак Гали агай җырларын:

«...Чиркәү болдырыннан менгән чакта,
Тез тамыркайларым тартадыр.
Өстәлләрдә тора дуңгыз ите,
Валлай-билләй, дуслар, капмадым,
Валлай-билләй, дуслар, мин капмадым.
Күкрәгемә пычак капладым...»

...Ә бер «сынык борын» болай дигән
(Соңра аны күпләр чәйнәгән):
«Рәчәй бөеклеге Себер җирен
Үзләштерү белән бәйләнгән...»

Һәм тагын агылган «романтиклар»,
Фахишәләр килгән, караклар,
Садә юрталарны кысрыклаган,
Пычрак, сасы, шыксыз бараклар...

Үз телен, гадәтен көчләп тагу
«Бөек халык»ка хас «яхшылык»,
Шулай кергән Себергә дә агып,

Безгә күптән таныш шакшылык.

Ә Себердә туфрак — юка торф,
Ни генә чәчсәң дә тишелми;
Агачкайлар үскән тотынышып,
Тик шуңарга урман ишелми.

«Суверенитет» дип сикерсәләр,
Укытырга татар иманын
Мәскәүдән чакыртып китерәм, ди,
Бер биш меңлек урыс ОМОНын.

Биш мең, бәлкем, хәйран хәтәр көчтер,
Иманы саф булса, нык булса,
Миллионлы армия дә көчсез,
Рухы, идеаллар чүп булса...

Кубарылып ерак-ераклардан,
Актарылып, ыргып, ашкынып,
Урам-мәйданнарга сыймас булып
Кузгалыр ул татар ташкыны.

Юкка чыгар шулчак сатлыкҗаннар,
ОМОНнары очар көл булып.
Без атарбыз ул көн чәчәк булып,
Кояшка карарбыз гөл булып!..

* * *

Ачыгыз тәрәзәгезне,
Тәрәзәгез булса.

*М. Әгъләмов*

Ачыгыз авызыгызны,
Тешләрегез булса,
Ябыгыз авызыгызны,
Акылыгыз булса.

Ябыгыз төннегегезне,
Төннәр салкын торса,
Ачыгыз кендегегезне,
Оятыгыз корса.

Тасрайтыгыз күзләрне,
Күзләрегез күрсә,
Миндәй шигырь иярләгез,
Сүзләрегез йөрсә!..

## Саба

Саба җилләре аралый
Тау битендә артышны;
Тауга мендем, таудан төштем,
Баса алмадым сагышны...

Безнең Саба якларында
Кызларның бите алсу.
Шул гүзәлләр арасында
Ник син генә ямансу?

Олы Мишә куенына
Кечесе агып төшә.

Әйдә, дустым, барасыңмы
Сулар кавышкан төшкә...

## Мөһаҗир җыры

*(Тәкълид)*

*Гаяз Исхакыйга*

Һавадагы киек каздан,
Син каян, дип сорадым.
Ул кычкырып җавап бирде, —
Мин утырып еладым.

*Халык җыры*

Һавадагы ак болыттан,
Син каян, дип сорадым.
Шул болыттан тамчы тамып,
Керфекләрем чыланды.

Кыйбла якка искән җилдән,
Син каян, дип сорадым.
Шул җил мине чәчләремнән,
Маңгаемнан сыйпады.

Һавадагы аккошларга
Эндәшергә кыймадым;
Тамып калган каурыйларын
Мин тезләнеп җыйнадым...

## Кәҗә монологы

Авылда чакта да сер бирмәдек,
Ягъни күз өстендә каш идем,
Урын һәрчак түрдә, алда булды,
Сарык көтүенә баш идем.

Көнләштеләр, чәйнәделәр гайбәт,
Имеш, бакчаларда урлаштым,
Авыл халкы кадерне белмәгәч,
Башкалага барып урнаштым.

Койрык игы дан түгел түгелен,
Әмма мөгезләр бит күрекле,
Ит комбинатында эш табылды,
Вазифама җәһәт күнектем.

Авыл сарыкларын каршы алам,
Алар мине танып тагыла,
Сугым залларына аяк баскач,
Арттан шартлап капка ябыла...

Яшерен ишектән чыгып таям,
Ә сарыклар кала, нишлисең,
Миңа дигән тагаракта печән —
Чәчәк-җиләкле, хуш ислесе...

Үземне мин сәясмәнгә чутлыйм,

Алар да бит миндәй калыккан,
Алар да бит, күпме зарыкмасын,
Рәхмәт ишетмиләр халыктан...

## Сәхнәләрдә «йолдыз», һай, ничәдер?

Ботыннан селкиләр җырлаганда,
«До-ре» түгел, «ду-ра» коела.
Шул кыз концертына билетлар бар,
Барабызмы бака туена?

Аллы-гөлле кофта кигән егет
Җырлый, чыга кәҗә тавышы;
Татарстан җирен күмәр, ахры,
Кәҗә тавышлылар сагышы...

Татар моңын тәмам җилгәрергә
Тагы да «йолдыз явы» килерме?
Абзыкаем, Мортаза Рәхимов,
Әллә ябасыңмы чигеңне?..

## Әдәбият дәресендә әңгәмә

— Төлке хәле көлке, ул җәнлекне
Һич тә гадел түгел табалау. —
Карга мактаганга — бер кабым сыр,
Ә кайда соң монда алдалау?
— Хикмәт шунда: иптәш-сабакташ,
Крылов каргага канатташ...

## Китапханәдә

Исемнәр алтынлап төшерелгән,
Хәтфә, ахры, тышлык — «туннары»...
Шүрлек-киштәләрне нур балкытып,
Тезелешкән кемнең томнары?

Безнекеләр! Үзебезнекеләр!
Бар да әдип, бар да депутат,
Нинди генә бүләк алмаганнар,
Өстәвенә кат-кат лауреат.

Әллә ничә кеше караш ата,
«Чалы кошы» «кунган» киштәгә.
Ә ул кулда икән, ярар, диләр,
Сугылып карарбыз иртәгә...

Чиртми халык теге китапларга,
Уелса да исем алтыннан...
Тукай китаплары өши сыман
Шулардан саркыган салкыннан.

* * *

Балта суга төшү — кайгы,
Очар кош тоту — шатлык...
...Халык җәүһәрләренә дә
Тирән сеңгән гыйбатлык...

* * *

Түрә булсам, мин җикерәсе
Өстәл төя-төя халыкка;
...Таракандай яшәп ятыш әле,
Валчык ташыштырып ярыкка...

* * *

Кабинет зур, машина шәп,
Гаме юк һичбер эштә;
«Зам по зәм-зәм» дип йөртәләр,
Килгән кунакларны сыйлап
Озату — аның өстә...

* * *

Күтәренке күлмәк, ачык кендек,
Төшеп бара ыштан дигәннәре...
Сигарет аралаш сыра имеп,
Кыю атлый милләт чибәрләре...

* * *

Кеше хакын басып калучы,
Нәҗесен мыскалга салучы
Игелек кылучы саналды,
Хәйрияче дигән дан алды,
Даны еракларга таралды...

* * *

«Яшьлегем, кайт, кайт кире», — дип,
Тумас борын картайганнар
И җырлыйлар әсәреп...
И мөгриләр көчәнеп...
Яшьлек кадерен белүчеләр
Йөзгә якынлашканда да
Яши яшьнәп, яшәреп...

* * *

Ерак йөрми бездән һәлакәт тә,
Кайчак дәва җанга җәрәхәт тә;
Яз, җәй, көз, кыш — һаман гел бер рәттә,
Алар түгел, ә без сәяхәттә!!!

Тормыш атлы гаҗәп сәяхәттә
Михнәте дә таныш, бәрәкәт тә;
Омтылабыз данга, шәрәфәткә,
Без әйбәт тә, бераз кабахәт тә...

## Йолдыз сүзе

Сафсатаны сәхнәләрдән җырлап
Сатасы килә;
Безгә тел тидергән каләмзатны
Атасы килә...
Сатасы килеп сатарга,
Атасы килеп атарга
Язсын!..

## Татар-башкорт көрәше

Нинди мәгънәсез атама —
«Татар-башкорт көрәше»;
Бертуганнар, агай-эне
Бер-беренә көндәшме?

Большевиклар мирасы ул
«Татар-башкорт көрәше»;
Бу шаукымның нигезендә
Хыянәт һәм көнләшү...

Байтак гомер дәвам итә
Дошманнар таккан «көрәш»;
Татар мәктәбен җимереп,
Уңыш казана кардәш...

## Көрәш

Кояш һәркемгә елмая,
Ул — гаделлек өлгесе;
Гадел җиңүчегә генә
Тәкә — кояш билгесе.

Бүләккә — кояш билгесе,
Борынгы чордан сәлам;
Сөлге җилферди колгада,
Сабан туена әләм...

Бабайлар баш булган чорда
Ауропа җирләренә,
Көрәш кураж булып күчкән
Шул кыйтга телләренә.

Уйнап кына җиңгән татар
Ятларның батырларын,
Болыннарын ямьләгәндә
Зиннәтле чатырлары...

Татар рухына ят булган
Егылганны типкәләү;
Сырт төшкәннәр кабат торган,
Җиңүчегә үпкәләп...

Хөсетлерәкләр баш ваткан,
Бәхәсләшкән, киңәшкән,
Хәрам һәм хыянәт керткән
Чиста, гадел көрәшкә...

Бер егылу чүп кенә күк
Меңне еккан татарга;
Форсат бирмәгәннәр аңа
Кабат торып басарга...

Башкаена төшкән күсәк,
Типкәннәр касыгына,
Ыңгырашу киртә түгел
Җәлладлар ярсуына...

Тарихны утка атканнар
Һәм язганнар яңартып:

Татарларга дегет сылап,
Ә үзләрен агартып.

...Курчак суверенлыктан да
Котлары төште ботка,
Ут йоттырды вәхшиләрне
Без теләгән әлифба.

Торырга ирек бирмиләр,
Типкәлиләр бүген дә.
Тик өмет йолдызы исән,
Исән татар күгендә!

...Сабан туенда ак сөлге
Җилферди әләм булып;
Кайтыр азатлык халкыма,
Ходайдан сәлам булып!

## Милләтеңә тидермә тел...

Милләтеңә тидермә тел,
Син түгел аннан олы,
Син аның тик бер бөртеге,
Син аның газиз улы...

Милләтеңә тидермә тел,
Сүзең дөрес булса да,
Әйткәнеңә әллә кемнәр
Кул чәбәкләп торса да.

Милләтеңә тидермә тел,
Түкмә-чәчмә белгәнең...
Әйе, ул күптәнге кошы
Рәчәй дигән төрмәнең.

Коллык үзгәртә холыкны,
Коллык вагайта җанны;
Нахак яккан ялалар да
Ерак тараткан «дан»ны.

Гаепләмә милләтеңне,
Мыек очларың чәйнәп;
Матур түгел, агай-эне,
Тукта сатудан гайбәт...

## Еллар узгач...

Истә адымымны саташтырган,
Иңгә канат куйган карашың.
Син бит мондый түгел идең, бәгърем,
Мондый түгел идең, җанашым?

Очраштык та тагын аерылыштык,
Сагыш бөреп алды күңелне;
Тәмам аптырадым: минме соң бу?
Минме соң бу, әллә түгелме?

* * *

Хәерчеләр күңелләрен
Җырлар җырлап ачалар,
Байлар исә шул моңнарны
Тыңлап сагыш басалар...

* * *

Эшче һәм игенче, сезнең базар
Төште инде, төште;
Элек галиҗәнап саналдыгыз,
Ә хәзер сез — пешка.

Попса җырчы, фахишә, спортчы,
Сезне бәхет басты,
Русиядән намус, иман, вөҗдан
Качты инде, качты...

* * *

Күлмәгеңне кычытканнан тукыт,
Сырышмасын дисәң тугрылар.
Керпе тиресеннән бүрек тектер,
Салдырмасын дисәң угрылар...

## Пушкин

Яндыра да, өшетә дә
Мәхәббәт ялкыны,
Бәгырь тамырына төшә
Көнләшү шаукымы.

Пушкинның нияте мәгълүм:
Үтерәм, дип барган,
Икесе дә яраланган,
Дантес исән калган...

Хак Тәгалә рәхмәте киң,
Шагыйрьне яклаган,
Җан кыюдан аралаган,
Исемен пакьләгән.

Башка азак көтсә, бәлкем,
Пушкин... тумас иде...
Туса да, Тукай зурларлык
Бөек булмас иде...

## Түрә фикере

Төкерсәң, кызган тимердәй
Чыжлый моның йөзе,
Эшеннән кауламый булмас,
Ямьсез карый күзе.

* * *

Бәхет — әкияттәге ат ул,
Ялына ябыш та капыл,
Атланып күбеккә батыр,
Вәт булырсың батыр,
Дип саталар акыл.

* * *

Үлән гашыйк тормышка,
Ташны этәреп шыта;
Кемдер баш ора шул ташка...
Яшәү күңелен болгата,
Үлеме дә укшыта...

* * *

Тузлы кабык җыештырып йөри
Утын әрдәнәсе янында;
«Ак каеннар, ник шауламыйсыз?» — дип
Җырлап куя шунда тагын да...

* * *

Түрә — гүя үрдәк,
Аңа кирәк күбрәк;
Бугазга ни сыйса,
Бөтенесен соса!

* * *

Сүз эзләп кесәгә керми,
Акча эзләп керә.
Артык яки ким җире юк,
Гап-гади бер түрә...

Атланып каулый законны,
Авызлыклап җигә;
Дөньяның арт шәрифенә
Кушаяклап тибә!..

* * *

Тегермән җил уңаена түгел,
Каршы якка тарта онны!
Ялагайлар түрәләргә
Оныттыра шуны...

## Хатын алдым

*(Такмаза)*

Хатыным Мичәнбаштан,
Сөйлимче исәр баштан...

Хатын алдым Сабадан,
Авызы киң табадан.

Хатын алдым Апастан,
Авызы зур лапастан.

Хатын ягы Аксубай,
Кызыл эчми, ак сорай.

Хатын алдым Норлаттан,
Күп гармунчы җырлаткан.

Хатын каласы — Чистай,
Һаман ятыйк дип кыстай.

Хатын алдым Мөслимнән,
Йөри, юньсез, өстемнән.

Хатын Түбән Камадан,
Борыны еш канаган.

Хатыным Мамадыштан,
Тасма тел, шома, куштан.

Хатын алдым Әтнәдән,
Туйдырды бер атнадан.

Хатыным ягы Сарман,
Миңа килгәнче арган.
Хатын алдым Балтачтан,
Үтерер, ахры, ачтан.

Хатыным Актаныштан,
Кидереп булмый ыштан.

Хатын алдым Әлмәттән,
Күпне күргән, әлбәттә.

Хатыным ягы Буа,
Төн дә төшләнеп буа.

Хатыным ягы Арча,
Бер сүз белми татарча.

Хатын ягы Кукмара,
Ир-ат күрсә уктала.

Хатыным ягы Чаллы,
Яшьлек еллары данлы.

Хатын алдым Казаннан,
Данны шунда казанган.

Хатыным Кайбычныкы,
Тавышы байгышныкы.

Хатын ягы Теләче,
Үбәсе дә үләсе!

## Диңгез кебек

Җир дә дулкынлана диңгез кебек,
Таш-кыялар шул ук дулкыннар;
Дулкын өстендәге күбек кебек,
Тау түбәләрендә ак карлар.

Кушымта:

Борлыкма, милләттәш, борлыкма,
Атар безгә дигән алсу таң;
Җиңү безнең якта булыр, дигән
Безнең бабайларга Чыңгыз хан...

Дала дулкынлана диңгез кебек,
Ак чәчкәләр гүя ак күбек.
Безнең атлар, безнең пар канатлар,
Ник очмыйсың, халкым, кош кебек?..

Кушымта.

Җыр да дулкынлана диңгез кебек,
Безнең моңнар — шул ук дулкыннар,
Моң яшәсә, без яшәрбез әле,
Татар җаны әле сулкылдар...

Кушымта.

## Бармы җаныгыз?

Авылдашлар сөйли: «Фидель эчә,
Маркс кәҗә урлап тотылган...
Ригел җиңеләйгән, ә Идеал
Асылынып үлгән тупылга...

Хаҗ кылмакчы, имеш, Кристина,
Киллер булып куйган Револьвер...
Катып үлгән беркөн Декабрина,
Ә Ревонер булган сутенер ...

«Татарстан яшьләре»ндә чыкты
Егерменче мартта узган ел
«Татар исемнәре исемлеге» —
Хет хурлыкка түзми егылып үл.

Айлы манаралар аударылгач,
Тоныклангач кыйбла күңелдә,
Бет, кибәктәй баскан милләт рухын
Коммунистик яңа исемнәр.

Ягъни зәхмәт безгә узган гасыр,
Унҗиденче елда кагылган;
Шул гомердән бирле сеңгән керне
Кырып юасы бар, сабынлап.

Эмма, Карл, Рамус, Гелий, Ампер,
Аринат, Бәнана, Дәвәрис,
Финзур, Финат, Эльзат, Эльмар, Римхәт,
Әлфис, Гөлдария, Фидарис.

Робин, Марлен, Ибен, Робсон,
Ралит, Дахьян, Дофак, Бермуд, Изотоп...
Мондый вәхшәт өчен яру фарыз,
Җиргә сузып салып, чинатып...

Катык сөртсәң эт яламас атны
Газиз баласына кем кушкан?
Телсез, денсез, рухсыз адәмнәрме?
Әллә урыслашкан бер куштан?

Әллә нинди сәер атамалар,
Кеше исемнәре түгел бу!

Мутантлашу галәмәте ләса
Мондый исемнәргә күнегү...

...Камил исемнәрне иске чутлап,
Күпләр таккан яңа «исем»нәр,
Тора-бара фигыль булып яки
Гыйбрәт булып күчкән җисемгә...

Кирәк бүген безгә Мөхәммәтләр,
Әмирханнар кирәк, Саттарлар;
Баласына милли исем куша
Иманына тугры татарлар!»

## Бәгъзеләребез...

Үлгән атның тоягыннан
Дагасын кубара.
Шул мөлкәтен, бәхет юрап,
Диварына кага...

## Трамвайда төш

*(Яшь язучы авызыннан)*

Ишек шакып кердем:
— Әйбәтме сез? — дидем.
Мөхәррир елмая:
— Ни апкилдең, кая?

Үсмәсме дип бәям:
— Китердем, — дим, — бәян.
— Пүч бәян, пүч нәсер,
Итәбез, — ди, — нәшер.

Янә, җитеп сәүис:
— Яздым, — мәйтәм, — пауис.
— Романга күч, дус, — ди, —
Пока бездә пус, — ди...

— Гәҗит-журналларда
Көнаралаш сүген,
Кичә бастылармы,
Димәк, ял ит бүген...

Форсат кулда чакта
Томнарың чыгарт, — ди, —
Авыз ачып торма,
Син бит депутат, — ди...

— Ким дигәндә ун том!
Дускай, булма үшән,
Су язып май чыгар,
Кәкрәй һәм көчән...

Язганнарың бардыр
Бәләкәй чагыңда,
Кош тизәге туплау,
Көл җыю хакында.

Чит телләрдә чыксын
Һәрбер сүзең, юлың.
Сөз байлыкны мулдан,
Кулда чакта җылым.

Милләт хәлен уйлап
Йөрмә чырай сытып,
Бәхет кошың — мандат,
Рәхәтен күр, мокыт!..

Куйдырт оперетта,
Төшерт киносын да,
Сәламәтлек барда
Төкер дөньясына...

Батма кайгыларга,
Катнаш бәйгеләргә,
Приз, бүләк таптыр,
Гел үзеңә тарттыр...

Мин — надан, дип торма,
Фәндә селтә кылыч,
Әкәдимик исмен
Ләктерергә тырыш...

Аһ, бу кондукторны,
Нинди төшне бүлде;
Депутат булмагач,
Билет алам инде...

* * *
Ак болытларга карыйм да,
Нигәдер моңаела;
Алар тормышны көйләгән
Бары җил уңаена...

* * *
Чын ир заты кайтып керсә — тансык кунак,
Өстәлендә сөйгән ашы бу чыгара;
Мәхлук ирдән — «чытык чырай, җимерек каш»,
Оча-куна сорау ала бусагада...

* * *
Мөхәррир тәфтишли һәр язганны,
Уздырмаска теләп хилаф сүз;
Колагы киртләнгән күп мәртәбә:
«Гаеп атта була һәм тәртәдә,
Дилбегә тотучы — гөнаһсыз!..»

## Кабат кайтмый икән...

Ерактан күреп алсам да,
Җанда ялкын кабына,
Әгәр карашына тарсам,
Аяк тая, чалына.

Беләм, аңа тиң түгелмен,

Шуңа да күрми уза,
Ә йөрәкнең үз туксаны:
«Тик ул гына!» — дип сыза...

«Без никадәр азрак сөйсәк,
Алар ярата күбрәк!»
Гаҗизлектән шул ысулга
Барып каплана йөрәк...

Үз-үземне инандырам
Аны яратмавыма,
Акылны гер итеп тагам
Хыял канатларыма...

Һәм тал корый, чишмә тына,
Тынып кала сандугач,
Инде очраса — абынмыйм
Һәм барламыйм көн тугач...

Беркөн мәгъшукам килә дә
Сыена кочагыма,
«Әйдә, бергә янабыз, — ди, —
Мәхәббәт учагында!..»

Ә мин гүя каккан казык,
Бер җылы сүз табалмыйм,
Дөрли учак, ә мин, тумран,
Кабыналмыйм, яналмыйм...

Җаннан сөюне бер сөргәч,
Ул кабат кайтмый икән,
Аның кайтмаячагы да
Инде моңайтмый икән...

## Хикәяләр

### Кирт

Шәйдулла игезәкләренең берсе генерал булган дигән хәбәр кәнсәләр янына җыелышкан авылдашларны кузгатып җибәрде.

— Әкият сөйләмәгез, ниткән генерал?— дип күтәрелеп бәрелде ат караучы Әхмәтсафа. — Болар бит минем күз алдында үсте, әбиләре, мәрхүм, «икесенә бер акыл» ди торганые.

— Иныстыйтүт тәмамлаган теләсә кемне укытырга калдырмыйлар, энекәем Әхмәтсафа, муен - тамырыңа бозау аягы, — дип карышты тимерче Баһави.

— Әкәләле имән булды ул Шәйди малае, — дип куәтләде аны тракторчы Фирдәвес. — Датсит микән һаман да, прафисырлыкка ук чыкты микән инде?

— КХТИны ШХТИ дип атамагайлары, бөтен Шабан малае, унны очлап чыгуга, шунда җиппәреләә, — дип күтәреп алды шофер Зиннур.

— Авылны имеп күрсәтә Рәсилегез.

— Балаңны армиягә җибәрәсең килмәсә, кесәне кашымый кая барасың?

— Безнең заманда, юеш сөлгегә тимер кашык бәйләп, күткә сугалар иде дә, присәге кабул чутланды. Хәзер алай ансат котылулар юк ди шул...

— Ә каян беләсең син аның имгәнен-иммәгәнен. Ул бит акчаны үз кулы белән сосмый, кирәкле кеше белән генә кавыштыра.

— Соңыннан бүлешмиләрдер дисеңме? Дурак!

— Үзеңне бел инде!

— Моның Рәзиле генерал булып чыгамы соң?— дип тел шартлатты моңарчы тын торган агроном Зариф.

— Әрмиядән сержант булып кайттың да, генерал иттеләр, ди, тот капчыгыңны.

— Әхмәтсафа дөрес сукалый, солдаттан өлкән сержант погоны тагып, КПСС сафларына алынып кайтты Рәзилләре, миңа килеп учетка басты, бик беләсегез килсә, — дип ачыклык кертте колхозның элеккеге партком сәркатибе, милли түбәтәй киеп алган Фәләх агай. — Сыңары укыган институтка мин сырлаган юлламаны тотып барып керде генералыгыз.

— Башымны чапмага бирәм, югары хәрби дәрәҗә Шәйди малайларына түгел! Рәвеш юк Габиныкыларда генерал булырлык.

— Ашыкма, галстугыңа басарсың, — дип, сүзгә кушылды зоотехник Хәләф. — Мин дә ишеттем бу җырны. Рәзил Шәйдулла улы Татарстанга генерал булып кайта, диделәр. Димәк, аны генеральный директор иткәннәр!

— Егетләр, карагыз әле, карагыз! — дип, зират ягына ымлады Әхмәтсафа. — Әллә оча торган тәлинкә төшә инде?

Башлар капылт шул тарафка борылды. Зират буендагы юлдан таудан түбән таба үтә дә кәттә һәм йомры дәү җиңел машина элдерә иде.

— Кемнеке булыр бу зәхмәт?

— Главаныкыдыр.

— Чүлмәгегезне эшләтегез әзрәк, —диде Хәләф. — Иманым камил, Рәзил кордашныкы бу. Шуның кайтышы.

...Рәзил Шәйдуллович Габиевның Казанда яңа эш урынында кайнаша башлавына ай узды, ә авылга кайтып күренергә һаман җай табылмый торды... Бердән бер көнне, төшке аш тирәсендәрәк, секретарь кыз Урал Җаңкаевның, кабул ителүгә өмет баглап, телефоннан шалтыратуын хәбәр итте. Атказанган сәнгать эшлеклесен көттереп, рәнҗетәсе килмәде Рәзилнең, җитмәсә, Себердә чагында күрешкәннәре, якташка булышыйм дип, бер-ике концертлык билетларын хәйран ару хакка оешмасы хисабына сатып алганы да булды.

— Ярар, уздырсыннар, — диде.

Ике минут та үтмәгәндер, халык теленә Җаңкай дип менгән артист пәйда булды һәм, колачын киң җәеп, елмаеп-балкып, Рәзилгә таба атылды. Бу кадәр якын итүгә Габиев битараф кала алмады, әлбәттә, урыныннан торып, ул да аңа каршы ярты булса да адым ясап өлгерде.

Татарстанда хәзерге җитәкчеләрнең яңача, чеченнарга охшатыпмы, христианнардан, әллә «братва»дан микән үрнәк алып, һәрхәлдә, «зәңгәрләрдән» түгелдер дип өметләник, битләрне битләргә өч кат турылап, арка сыйпап күрешә башлауларыннан ул хәбәрдар иде... Җаңкай да шуны куды, туган якка кайтып, уңышлы «посадка» ясавы белән котлады, тиздән концертлары узасын әйтеп, чакыру билетларын өстәленә ыргытты һәм, сүз иярә сүз чыгарып, гадәти билетларын оешма чутыннанмы, профсоюз хисабынамы сатып алуда булышуын гозерләде.

— Сиңа кадәрге генерал ярдәменнән ташламады, бозмыйк традицияне... Син дип сөйләшкәнгә ачуланмыйсыңдыр бит?

— Әлегә юк, — дип елмайды Рәзил.

— Билет бәһасенә исең китмәсен, сезгә дә яшәргә кирәктер, ярты хакын түләсәгез, менә моннан була, — дип, бугазына сызып күрсәтте ул, кет-кет көлеп. — Ә калганы не мое дело...

Рәзил яңа урынга ияләшә төшкәч карап карарга вәгъдә бирде һәм бергә туган авылын урап килергә тәкъдим ясады...

— Әни ярата син җырлаганны, аңа алып кайтыр өчен тансыграк күчтәнәч тапмыйм.

— Әниегез ни атлы?

— Мәбрүрә.

— Матур исем икән.

...Юләргә закон язылмаган, имеш ки. Ничек кенә язылган әле. Ә менә хәерчегә гел каршы җил, түрәләргә һәрчак уңай. Тизлекне ике йөздән киметми чапкан иномаркага чакрым саен диярлек очрап торган ГАИ хезмәткәрләренең ник берсе игътибар итсен... Кем әйтмешли, күз ачып йомганчы кайтып җиттеләр.

— Бәй, син Шабанныкы, штүли?— дип куйды Җаңкаев, юл читендәге күрсәткеч тактага игътибар итеп.

— Ә нәрсә?

— Бу үзешчән композитор Рәкыйп Заһитов авылы түгелме соң?

— Сез баҗалар мәллә?

— Дөнья хәлен белеп булмый. Ә болай — иҗатташ дус. Быел эстрада фестивалендә ул язган «Казаным» җырын җырлап, беренче урын эләкте бит, саф алтыннан койган былбыл сыны тоттырдылар.

— Рәкыйпкә дә берәр нәрсә тәтедеме соң?

Җаңкай авызын зур ачып иснәнде, кулларын як-якка ташлап киерелеп алды.

— Фестиваль оештыручылар авторларны бар дип тә белми, безгә, башкаручыларга салыналар.

— Авылдашны рәнҗетмәгәнсеңдер ич инде?

— Беренче рәзрәт буенча офисымда, кунак бүлмәсенә алып кереп, сый-хөрмәт күрсәттем, коньяк чыгардым, закускага икра, кайнар второй. Аннары юкә балы белән чәй. Киткәндә кулына милли түбәтәй, сурәтем төшкән футболка, концертларым язылган кассеталар, үзем турында альбом һәм башка шундый истәлекле әйберләрне пакетка дыңгычлап тутырып кулына тоттырдым һәм әнә бара юлың... Нәфеснең чиге юк, ашаган белми, тураган белә.

...Рәзил кәнсәләр янында туктап авылдашлары белән күрешәсе итте.

Җаңкай исә кулларын кушырып югары күтәрде һәм:

— Общий привет, — дип сәламләде.

— Хәлләрегез ничек соң, авылдашлар? — дип кызыксынды Рәзил.

— Алда — гөл, артта — чәчәк, сыртта — койрык, ява боерык, энекәш.

— Рәтле эш юк. Булса, түләмиләр. Җиргә инвестор хуҗа урыннарда эш хакы тама бугай әз-мәз.

— Көшел авылын әнә инвестор — районның элеккеге башлыгы ботлап алды. Вәт әйткән ул, җиргә мин хуҗа, кая кушсам, шунда эшләрсез, малларыгыз минем көтүлеккә чыкса, аттырам, дигән...

— Ә без әлегә ике арада. Хуҗалык рәисе китмәгән, инвестор килмәгән дигәндәй.

— Ике арада булгач ярый әле ул, — дип авыз ерды Жаңкай.

— Нәрсәгә дип җыелыштык соң әле, энәдән-җептән киенеп? Берәр тирә-як авылда Сабантуй үтмидер бит?— дип кызыксынды Рәзил.

— Кем әйткәндәй, көн дә бәйрәм, көн дә туй хәзер. Узган атнада район үзәгенә спорт бәйрәменә йөгерешкә җибәргәннәр иде, өченче урынны алып кайттык, бүген менә «Җырлыйк әле» конкурсына ашыгабыз.

— Ә кайда гүзәл затлар? Аларсыз кызык булмас бит сәфәрегездә, — дип көлә-көлә тагын сүзгә катышты Жаңкай.

— Хатын-кызлар мәктәп ашханәсендә чәй эчә, шулар төялеп килгәнне көтәбез, — дип җавап күндерде Зариф ага.

— Прафисианал буларак сезгә миннән киңәш, — диде Урал. — Әгәр колак салырга теләсәгез?

— Безнең колаклар күптән салынулы.

— Колак кына салынса ярый әле ул, — дип, тагын хихылдап көлде кунак. — Туфан абыйның «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә бер җыр бар. — Жаңкай әкрен генә җырлауга күчте:

Без җырлыйбыз шырдыйны,
Шырдый белән бырдыйны;
Җырламас идек шырдыйны,
Тыңлаучылар шыр тиле!

— Бу дурак әйтте диярсез, жюриның күзенә карап, шушыны башкарсагыз, беренче урын һичшиксез сезнеке! — Һәм популяр җырчы, үзе әйткәннәрдән янә ямь табып, тагын шыркылдарга тотынды.

Әмма аңа кушылучы табылмады. Жаңкай, ялгызы көлгәндә чәчрәп чыккан күз яшьләрен кулъяулык белән корытырга керешкәч, Әхмәтсафа, үтә дә җитди кыяфәт ясап, күндәм, туң тавыш белән:

— Без әле тыңлаучыны шыр тилегә санар дәрәҗәгә күтәрелмәгән, «йолдыз әртисләр» ипиенә керәсебез килми, — диде.

Аның белдерүеннән соң беркавым уңайсыз тынлык урнашып торды. Авылдашлар башта берәм-берәм пырх-пырх килде, аннары дәррәү көлә башладылар. Рәзил дә авылдашларына кушылды.

— Шабаннныкыларның авызына шайтан төкергән диюләре хак икән, — диде җитдиләнеп калган Урал Жаңкаев. — Рәхмәт барыгызга да. Үз этлегегез үзегезгә әйләнеп кайтсын!

— Әле авылдашлар белән Рәсил Шәйдуллычны мактап тордык, — дип, эре сирәк саргылт тешләрен күрсәтеп елмаюында булды Әхмәтсафа. — Шабан мокытларын кем кеше рәтенә чыгарыр иде ул булмаса, дибез...

— Монда булырга тиеш иде ул.

— Күренә. Кичә урамда каз куып йөрде.

Казаннан кайтучылар, кабат машинага утырып, урам буйлап китеп югалгач, әңгәмә иске эргәсенә керде.

— Егетләр, үзегез сиздегез микән, чүгәли төшеп күрештегез генерал белән, — дип ирештерде Хәләф авылдашларын, — чалбар төбегез җиргә тиеп-тиеп алды.

— Тегесе кем булды аның?

— Радио тыңлаганың юкмыни бер дә?! Татарстанның атказанган артисты Урал Жаңкайны да танымагач, культурадан нык артта калгансың син.

— Ә-ә-ә... «Кешеләргә ярдәмчел, нык булыша» диләр бу Жаңкаевны...

— Син, Әхмәтсафа, алдашкан чагыңда сикергәләп куя торган бул әле, юкса кеше ышандырырсың.

— Гәҗиттән укыдым дип торам!

— Тәлгать Нәҗми әйтмешли, анда ни язмаслар.

— Һәй, синең белән...

— Кызма син, башта яшьтиеңне тыңла. Аннары селтәрсең тәпиеңне. Жан көеге ул сезнең Жаңкаевыгыз. — Хәләф, янәшә-тирәсендәгеләргә күз ташлап, үзенә төбәлгән карашларны барлады, сүзенә игътибар дәрәҗәсен чамалады һәм ачыклаганыннан канәгать калып дәвам итте: — Ишеткәнсездер, узган ел Казанда бальниста, ыркыбыда, пычак астына керергә туры килде. Терелдең дип чыгарып җибәргәннәр иде, юлда автобуста кесәне «чистартканнар». Инде нишләргә? Әхмәтсафада

гына түгел, бездә дә грамыт бар, гәҗит укыйбыз, ә анда Җаңкай хакында, бик тә йомышлыклы дип, өзми-куймый авыз суы корыталар, кыскасы, сораша торгач, офисын таптым моның, коператиф техникумы янында гына икән. Мендем ничәнчедер катка, кердем приумныена. Шунда утырган кыска япкылы кыз бала әйтә, әлегә ул юк, әмма тиздән килергә тиеш, көтегез, ди. Көттем, көтек булганчы. Килде бу, җилләнеп-давылланып. Сөйләп бирдем хәлне. Тыңлады. Аннары шаркылдап көлде һәм әйтте:

— Абый, мин Кыш бабай түгел бит бүләк өләшеп утырырга, үз проблемаларыңны үзең хәл ит, үземнеке үземнең дә баштан ашкан, — ди. Кулы белән менә болай сызып күрсәтә.

— Бер тиен дә бирмәдеме?

Хәләф баш чайкады.

— Ә ничек кайта алдың соң?

— Кире ыркыбыга барып, шундагы таныш авырулардан әҗәткә сорадым...

Гайбәт сату күпме дәвам иткән булыр иде, авылның гүзәл затларын төягән «пазик», тузаннар туздырып, боларның өсләренә менә язып килеп туктады, һәм, гәптәшләрнең очлы терсәкләре эшкә җигелеп, салонга алданрак үтү өчен дау башланды...

...Мәбрүрә апа, кадерле кунаклары бусагасыннан үткәндә, токмачлы аш булдырып йөри, ә мунчасы сәгать ярым элек үк томаланган иде инде. Ул Уралны бигрәк тә үз күрде, ашны аңа тирәнрәк савытка мулрак итеп бүлде, итнең иң тәмле билдәмә турын да аның тәлинкәсенә шудырды.

Урал сынатмады, шабыр тиргә батып ашап бетерде һәм, тыныбрак калган өйне яңгыратып:

— Мәбрүрә апа, яп-ялан аяк, токмачың тәмле булган! — дип кычкырды.

Тамаклар ялганып, бераз чылана да төшкәч, Җаңкай кулына баянын алды. Җыр арты җыр агылды.

— Апаем, әйдә «Урсал тау»ны? Мин бит Әлмәт ягыннан, Габдрахманныкы, — дип куйды күзләре яшәреп киткән Мәбрүрә апа. — Бүтән җырларыңны да яратам, үскәнем, әмма монысы үзәкне бигрәк өзә...

Җыр азагында калын кәгазь папка күтәргән Рәсил мышнап кайтып керде. Рәзилне: «Нихәл, картлач!» — дип сәламләде, ә Урал белән, гомер буе аралашкан кешесен күргән сыман, аркасыннан кагып: «Һайт, сәхнә аферисты!» — дип көлә-көлә күреште. Мич артында кулын юганда да туктамый такылдады.

— Әллә авылга макулатура җыярга кайткан идегез?— дип сүз кыстырды Урал.

— Папканы әйтәсеңме? Менә Рәзил кушканны үтим. Генералны тыңламый булмый.

— Үзең өчен йөгерәсең. Авылны коткару — синең идея...

Мунчада чабынып чыгып болдырда чәйләгәндә, тагын сәнгать хакында сүз китте...

— Үзешчән сәнгать безнең институтта да бар ул, Җаңкай әфәнде, — дип башлады Рәсил Шәйдулла улы. — Үземнең катнашкан чаклар булды. Марҗа кызлары белән бер хорда «Шауласын, гурласын безнен җыр» дип суза идек. Истә, бер концертыбызны әзерләшергә режиссер ялладылар. Ә бу сценарий буенча каулый. Имеш, башта Сабан туена бирнә җыйган атлы кыланасы, шул эргәдә бер-бер артлы номерлар башкарыла. Мин сорыйм моннан, нишләп концертны кешечә, конферансье алып барса ярамый, дип... Ә ул, эх, Рәсил абый, ди. Әгәр, ди, ялт иткән, тигез дәрәҗәдәге номерларыгыз булганда, сез әйткәнчә кулай да, ә монда шырды-бырдылар байтак, колибрлары төрле, шуңа күрә тамашачыны аларына да түздерү хакына сценарийсыз булмый, ди.

— Монысы минем бакчага тәгәрәтелгән таштыр инде?

— Хикмәт синдә генә түгел. Без яшь чакта, төрек язучысы Ришат Нури Гүнтекиннең «Чалы кошы» дигән әсәрен халык егылып укый иде. Баксаң, автор үз илендә яшәмәгән, җәсәде дә чит мәмләкәттә күмелгән. Ә романы аның Төркиягә, төрек халкына мәхәббәттә аңлашуына кайтып кала. Мәһдиев әсәрләренең дә хикмәте шунда. Халык ярата, димәк ки, ихлас автор ихлас җавап хисләре уятуга ирешкән. Илһам, Хәйдәр, Таһир Якуповлар җырлавы да халкыбызга мәхәббәттә аңлашу иде ул. Ә хәзерге иҗатта андый йөк юк шикелле...

— Туктале, Рәсил, — дип, Рәзил сүзгә кушыласы итте. — Син чын сәнгать белән бизнесны бутыйсың бугай. Миңа калса, концерт ул — акча эшләү проектын тормышка ашыру чарасы. Татар эстрадасының хәле әллә кем түгел. Һәм без әзрәк булышмасак, әле болар ач та калырга мөмкин.

— Рәзил абый дөрес әйтә, ул безнең хәлне аңлый, — дип сүзгә кереште Урал. — Шәп классик җырлар белән тамашачыны җыеп та булмый хәзер. Барыбыз да тырыштык анысы тамашачыны тәрбияләүдә. Зәвыгын да бозганбыздыр. Әмма бездән Мәдәният министрлыгы өчен эш сорау урынлы түгел. Без эшләгәнне үзләренә авыштырып кына йөрмәсеннәр, эшләсеннәр. Яки түләсеннәр акча, сценарийны бөек драматургтан яздырырбыз, ә сәхнәгә тамашаны танылган режиссер куяр, һәм ул очракта концертыбыз сәнгатьнең иң югары таләпләренә дә җавап бирер. Менә сез дә, Рәсил ага, соңгы елларда үтә дә фәһемле белгечләр, текә галимнәр чыгарабыз дип шапырына алмыйсыздыр? Чөнки вузларга башлыларны түгел, ә кесәсе сай булмаганнарны җыясыз. Имтихан, зачет, курсовой эшләр өчен акча каерыла. «Студентның акылы — кесәсендә. У.Җаңкаев». Шулай дип институтыгыз диварына яздырсагыз, мин бик мәмнүн булыр идем.

— Гаепләүләрегез миңа кагылмый.

— Белмим, белмим. Авылдашларыгыз мактап бетерә алмый үзегезне. «Шабан сарыкларын сез кеше итәсез» ди алар...

— Ярый, тынычланыгыз, — дип арага керде Рәзил. — Исәп: бергә бер. Безгә кузгалырга вакыт. Кая, папкаңны бир әле?

— Монда копияләр, төп нөсхәләр теркәү палатасында.

— Сүз нәрсә хакында бара? Миңа белергә ярыйдыр бит?

— Туган авылны сатып алмакчы булабыз. Рәсил балык күлләре ясыйм дип хыяллана. Халыкны эшле итәм, эшкәртү цехлары ачам, сәүдә нокталары булдырам, ди. Мул итеп иген икмәкче. Аның планнары зурдан.

— Әйдә, алайса, романтик хыяллар хөрмәтенә тагын берне тотыйк та кузгалыйк. Китүчеләр китәр, калучылар калыр. Шулаймы, Мәбрүрә апа?

— Шулай, апаем.

Урал белән Рәзилне Мәбрүрә апа һәм Рәсил урамга озата чыктылар. Күпмедер юл узгач, җырчы телгә килде:

— Икмәк сатып мантып буламы соң хәзерге шартларда? Минем Әнәс абыйның амбарында узган елгы ашлык бетләп ята. Алучы юк, ди.

— Рәсил берәр ел очынып алсын инде. Аннары, көймәсе комга терәлгәч, миңа дәвам итәсе булыр. Ул колбасаны — иттән, кибеттәге сөтне сөттән ясыйлар дип саташа.

— Ә син нинди юлны сайламакчы соң?

— Юл берәү генә. Заманча техника, заманча технологияләр. Һәм дуңгызчылык.

— Ә авыл халкы кул куярмы соң мондый эшкә? Монда бит мөселманнар яши.

— Башта берәр мәчет салдырмый ярамастыр... Бабайның исемен куйдырам. Габи мәчете дип.

— Заманча технологияләр кертелгәч, халык кимемәсме соң?

— Авылның перспективасы юк, дустым, ул бетәчәк... Әлегә әнә йөгерешкә барсыннар, җырласыннар...

...Мәбрүрә апа ул төнне йокыга китә алмый озак борсаланды. Шәйдулласы исенә төште. «Агач коммунист» дип ирештерәләр иде мәрхүмне авылдашлар, коммунизмга ышана иде. Малайларын да шул рухта тәрбияләргә тырышты. Тигезлек, гаделлек хакына хәтта бүләкләрнең дә гел бертөрлесен ташыды. Бермәлне шулай Рәзил белән Рәсилгә тәгәрмәчле ике уенчык ат алып кайтты. Рәсил бүләген кадерләми, урамда да уйнаган җирендә онытып кергәли. Аннары Рәзилнекенә барып тотына. Көннәрдән бер көнне Шәйдулла күрә: Рәзил пычак белән уенчык атның муенын ышкып маташа.

— Нишлисең, улым, ат суясың мәллә?— дип кызыксына Шәйдулла.

— Кирт ясыйм. Минеке!— ди Рәзил...

## Олы юлның тузаны

Хатын-кызны гайбәтче дигән булалар булуын, әмма бу өлкәдә өстенлек гүзәл затларда түгел шул.

Әле атна-ун көн элек яшьтиләр белән туган авылыбыз инеше ярына чыгып, балык шулпасы чөмереп, үткәннәрне искә төшереп утырдык. Әйтсәң — сүз, төртсәң — күз... Өчле-тугызлыга укып

йөргән Әхмәтебез генераль директор булган һәм вәгъдә биреп тә һаман кайтып җитмичә, безне көттереп интектерә. «Төгәллек — корольләр итагате» диләр дә, күрәсең, бу завхоз Сәгыйть малаена әлегә кагылмый.

Заһит та үзен тапкан, җирле бизнесменнарга шәхси «КамАЗ»ында йөк ташый икән, төшеме дә ару бугай, су буена дүрт ишекле «Нива»да рәхим иткән. Мин исә, мәктәптә гел бишлегә укып — алтын медаль, ә вузда кызыл диплом алган кеше һәм оешмабызда әйдәп баручы белгеч тә булгач, бүтәннәрдән бик үк калышасы, кем әйтмешли, йөз белән туфракка капланасы килмичә, кредитка «алтылы» алган идем, милиция майоры Хөснетдин зәңгәр төстәге өр-яңа «Ока»да, авылыбызда укытучы булып калган Фәрит ат җигеп, ә Казанда кайсыдыр газетадамы-журналдамы эшләүче шагыйрь дустыбыз Зиннәт төпчек энесенең сәпитенә атланып килгән. Утыра торгач, кемнең машиналы, ә кемнең машинасызлыгы бераз онытыла да төште, телләр чишелде, сүз арты сүз, уены-чыны-гайбәте бергә үрелде...

Хәтәр утырабыз. Аскан казанда яңа суйган сарык итеннән дымлама, учак уртасында каплап куелган чиләктә бәрәңге пешә, кыяры-помидоры, кишере, ипие-тозы — һәммәсе җитеш.

— Егетләр, Әхмәт тәки кайтып җитмәде, нишлибез?— дигән сөаль куйды Фәрит.

— «Әбизәтелне кайтам» дип миңа шалтыратты, көтик, — мин әйтәм.

— Машинаң төсле булма инде, — диде Зиннәт.

— ...?

— Машинаң «шестерка» түгелме соң синең?

— Егетләр, матур гына утырыйк, — диде пәһлеван гәүдәле Хөснетдин һәм Зиннәткә акаеп карап куйды. — Кемнең «шестерка», ә кемнең «мужик» икәнен бүтән җирдә ачыкларсыз.

— Алай матур карама, Хөснетдин, өстеңдәге форма болай да барьер тудыра, шуңа күрә генә сиңа мәктәптә чактагы кушаматың белән эндәшергә кыймый утырам. Аннары, башлый торыйк кына димәкче идем. Безнең Әхмәт эчми дә бит ул.

— Китче?— дип куйды Хөснетдин, тел шартлатып, һәм миңа борылды. — Чынлапмы? Син бит шуның фирмасында кәкрәясең?

— Капмый диярлек.

— Башлыйк дисез инде, алай булгач...

— Хәтерлисезме: мәктәптә Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрен үткән идек. Без дә, бергә уйнап үскән гап-гади малайлар, кырыкка төрләндек бит, ә!

— Без бар да бер чама. Ә Әхмәт чынлап та югары үрләде!

— Узган атнада син шуның «Мерседес»ында йөргәнсең, диделәр, кайларга бардыгыз инде?— дип кызыксынасы итте майор Хөснетдин.

— Ныртыга. Зәгыйфь акыллы балалар йортына. Ул анда студент чагында шабашкада эшләгән булган икән.

— Бергә эшләдек, — дип әңгәмәгә кушылды Фәрит. — Безнең бригадир булды. Без, биш студент, анда бер җәйдә ашханә, йокы корпусы һәм склад төзедек.

— Биш кеше дисеңме?

— Үзебез генә түгел, подсобный эшләргә дип, балалар йорты директоры шундагы өч малайны бирде. Әхмәт — коры халык бит ул, кәҗә майларын чыгартты барыбызның да.

— Ә теге бичараларга акча түләмәдегез инде?!

— Шуларның берсе утырып чыккан икән, «Мин төрмәдә дә эшләмәдем, барыбер эшләмим» дип чатакама килде. Ну, Әхмәт — Сәгыйть малае, җикте ул аны да күпме кирәк...

— Ә акчаны түләмәде, — дип үзенекен бөкте Зиннәт, күзләрен кыса төшеп, үҗәтләнә барып.

— Бездән ким алмадылар. Ә теге утырган малай «Үз гомеремдә мондый акча күргәнем юк иде» дип елады.

— Нәрсә-нәрсә, Әхмәт — гадел кеше, — дип гөрелдәде Заһит. — Шәп егет ул!

— Синдә комплекс неполноценности аңа карата, — дип елмайды Зиннәт. — Чөнки Сабан туйларында ул сине сыртыңа салды.

— Бер тапкыр.

— Җиткән. Син бит аннан егерме килога авыррак түгелме соң?

— Чиста көрәшә... Аны башта, хәлле чакта атып калырга кирәк. Вакытны ычкындырсаң — беттең. Кая, күтәреп куйыйк булмаса, шул хөрмәткә...

Хөснетдин тустаганнарга янә хәмер койды, һәм без тешкә йомшак нәрсәне уртлап куйдык.

— Әнә килә Әхмәтегез, — диде Зиннәт.

Дөрестән дә, тау башыннан әллә ничә фара яктырткан дәү машина төшеп килә иде.

— Кыланып та күрсәтә Әхмәдиша, — дип сызгырып куйды Зиннәт. — Әле «Мерседес»та кайта, әле «Тойота»да, әле джипта... Югыйсә аның дә әтисе колхозчы гына лабаса.

— Һе, аның каравы аның бабасы кулак булган, — диде Заһит. — Кан. Бернишләр хәл юк.

Ул арада танк хәтле джип, ярты болынны тутырып, минем «алтылы» янына туктады. Әхмәт ашыкмый гына машинасыннан төште, кулына бер катыргы тартма алды һәм, елмаеп-балкып, безнең якка атлады. Учак белән матавыкланырга керешкән Зиннәттән калганнарыбыз зур дәрәҗәгә ирешкән дустыбызны басып каршыладык. Әхмәт әрҗәсеннән күз күрмәгән, ханнар исеме белән бәйле аракылар, шәп ат казылыгы, ысланган балыклар, җиләк-җимеш, яшелчәнең әллә нинди төрләре килеп чыкты. Әхмәт тәненә сыланып торган спорт киемнәреннән иде: ул зифа буй-сын, ул якты караш, бер бите уелып бата торган матур йөз — ханзадә дип торырсың!

— Җитмәсә, машинада гына, тагын алып килербез...

Тиз генә стаканнарга хәмерне койдык һәм берәрне каплап куйдык. Фәрит учакта чиләк каплап пешергән ак күзәнәкле кызыл бәрәңгеләрне табын уртасына бушатты. Әхмәт үзен гади тота, бәрәңгене кабыгы-ние белән генә авызына озата. Алай да ул сөйләгәндә барыбыз да диярлек бриллиант тешле авызына карап торабыз, соңгы дөреслекне ул әйтеп бирер төсле. Укытучы Фәрит тә аннан нииндидер хакыйкатьне ишетергә тели.

— Әхмәт туган, ачуланма, бер мәсьәләне ачыклыйк, — ди. — Менә син уртача гына укыдың һәм әнә нинди тауга менеп киттең. Мин шәп укыган идем дә хәзер хезмәт хакымның күпмелеген әйтергә дә оят.

— Син генә түгел, академиклар, профессорлар шул хәлдә, парин, — ди Әхмәт, күзләрен кысып һәм елмаеп-балкып. — Мин генә дип йөрмә, бөтен акыллы кеше шул хәлдә.

— Аларда эшем юк. Менә мин кайда ялгыштым, юллар кайда аерылды?

— Үзгәртеп кору чоры авыл урамыннан тарттырылган печән эскерте сыман узды бит. Кемнәрдер шәп йолыкты, кемнәр бер-ике учма эләктерергә өлгерде, ә кемнәрдер иренде һәм кибән узып киткәнне тәрәзәдән күзәтеп калды. Чәй шупырып... Иренмәскә, баскан килеш йоклап йөрмәскә, уяу булырга кирәк, агай-эне. Уңышка ирешкәннәрне сүгеп йөрүдә фәтва аз.

— Сүгәбез анысы. Сине генә сүгеп тә булмый.

— Нишләп булмый?

— Беренчедән, яшьти.

— Ә икенчедән?

— Икенчедән, авылны кайгыртасың, бөтен урамнарны, тыкрыкларны асфальтлатып бетердең, чишмәләргә кадәр сукмак түшәттең. Мәктәпкә компьютерлар кайтарттың, газ керттердең һәм башкалар, һәм шуның ишеләр. Нәрсәгә омтыласың, ник боларны эшлисең? Тәти күренергә теләүме бу, әллә башкамы, яшьти?

— Комплекс неполноценности, — дип мөгрәп куйды бераз исерә төшкән Зиннәт дустыбыз. — Бу «яңа урыслар» димме, «яңа татарлар» микән, әлеге кавем машиналар, йортлар, тагын әллә ниткән нәмәкәйләр җыя. Җыя, җыя, ә канәгатьлек хисе килми. Аптырагач, акчага кәрт суга, үлем белән шаяра башлый. Алар да алмый башлагач, эч пошканнан яхшылыкта ярышырга керешә.

— Ә моның нәрсәсе начар соң?— диде Заһит, кырыс кына. — Игелекле юлга керү начармы?

— Егетләр, кызмыйк әле, — диде Әхмәт, көләчлеген һәм тынычлыгын тамчы да җуймыйча. — Берәрне тотып куйыйк башта. Әйдә, Зиннәт дус, чәкештерик әле. Син инде безнең электәнге лидер, күрсәт егетлегеңне. Менә монысы икенче эш. Булдырасың икән ләбаса. Мин бит бик яшьли эшләргә генә түгел, ә акча табарга да өйрәндем. Студент вакытта җәй айларында шабашкага йөрдем. Кстати, Путин да шуннан башлаган. Шабашка, беренчедән, дисциплинага өйрәтә, көн дә иртүк биштән торып, караңгы төшкәнче эшлисе бар. Кулың эшкә ята башлый, агач, таш, һәртөрле монтаж эшләренә. Аннары

проект-сметаның ни икәненә төшенәсең, заказчыдан акча каерырга өйрәнәсең. Тормышта кем нәрсәгә омтыла, шуңа ирешә, егетләр! Берегез — шагыйрь, берегез укытучы яки инженер булам дип хыялланды һәм ирештегез! Ә бабай әйтә иде миңа бәләкәй чакта, их, улым, дия иде, безнең өйне тартып алып, мунчага сөреп чыгарган авылдашларга яхшылык эшлисе иде, ди торган иде. Атаң тырыша, әмма мантый алмады, син бай булырсың, синең әбиең дә юк-бар кеше кызы түгел, күкәйче Габделгани кызы иде, ди торган иде... Мин бабайның өметен акларга, нәселебезгә лаек дәрәҗәгә, шуңа нигез булырлык мөлкәткә омтылдым... Институт тәмамлап эшкә башлаганда, мактана димәгез, үземнең начальниктан ярлы түгел идем. Машинаны мин өченче курста укыганда ук, акыллары бик үк камил булмаган балалар йорты бар бит әле, шунда эшләп алдым.

— Мин дә синең бригадада эшләдем ул чакны. Кәҗә майларын чыгарттың син безнең, — дип куйды Фәрит, ат казылыгына үрелеп.

— Башкалардан артык эшләмәсәң, берәү дә сиңа кауларга ирек куймый. Кабатлыйм, егетләр, кеше омтылганына ирешә. Ә бит кемнәрдер бу дөньяда инженер, укытучы, табиб кына түгел, ә хан, король булам дип тә килә. Һәм ирешә дә! Ал Чыңгыз ханны. Әтисен үтерәләр. Ятимлектә, ач-ялангач үсә. Әмма әнисе аңа, синең атаң даланың затлы аксөяге иде, дип сеңдерә, һәм егет, үсеп җиткәч, башта үзенә дуслар, фикердәшләр туплый, шуларга лидер була. Аннары әтисенең мөлкәтен кайтара. Ә тора-бара хан була һәм ярты Җир шарын яулый, хисапсыз күп халыкларның патшаларын үзенә тез йөгендерә. Аксак Тимер дә шулайрак башлый. Корольлек, ханлык, империяләр өчен көрәш җир биләмәсе кысаларында гына бармый. Америкада Рокфеллерлар — нефть, Морган — корыч кою өлкәсендә, Германиядә Флик завод-фабрикалар акцияләрен әвеш-тәвеш китереп, ә Билл Гейтс компьютерлар җитештереп «король» булды. «Битлз» ансамбле, «АББА», Майкл Джексоннар, хәтта Крутой, Алла Пугачевалар да шул өммәттә.

— Алайга китсә, татарның да алар ише үзенә күрә кәрүлләре, ханбикәләре бар.

— Әлбәттә!

— Араларында шәрәләре дә бардыр.

— Ихтимал.

— Ә син корольлеккә дауны бәрәңге, сатудан башладың инде.

— Моның ние начар? Әйе, без бәрәңгене, августта ук казып алып, Казанга илтеп сата идек. Соңарсаң, йә бәя төшә, йә саттырмыйлар. Әтинең бүтән керер җире булмаган инде, һәм ул байтак авылдашны шулай акча эшләргә өйрәтте дә. Банда оештырып, кеше талаудан да башлый кайберәүләр.

— Узган атнада Зәет белән Ныртыга, балалар йортына баргансыз икән.

— Шундагы балаларга акча өләште, — дидем мин.

— Тишек бер тиенлекләрме?— дип кызыксынды Зиннәт.

— Биш йөзлекләр, — дидем мин. — Кулларын сузып торалар, парин. Аларга карап, минем дә сиздерми генә шулар арасына кереп басып кул сузасым килеп куйды.

— Дурак!— дип читкә төкерде Зиннәт. — Соң, аларны директоры йә шуның шоферы алдап-йолдап җыеп алачак бит.

— Нәкъ менә директорлары, акча өләшергә кирәкми, көчлерәкләре талап алырга мөмкин, — дип, Әхмәтне туктатты да.

— Мин аларга йөзләп пакет бүләк озатырга булдым, — диде Әхмәт.

— Эх, егетләр, күрсәгез сез ул балалар йортын, бөтен җире евро, курорт — шифаханә дип торасың, — дип, шунда күргәннәремне тезәргә ашыктым. — Ул фонтан дисеңме, күлендә аккошлар йөзә, хәтта читлектә маймыллары да бар. Безнең районның главасы да, балаларга берәр нәрсә алырсың дип, шул мәктәпнең директорына узган җомгада җиде меңен кесәсеннән чыгарып биреп киткән.

— Заманалар үзгәргән, — дип куйды Зиннәт, авызын кыйшайтып. — Моннан бер ун ел безнең районда эшләп киткән Фаил Юнысычны хәтерлисездер.

— Малае бездән ике сыйныф түбән укыган иде. Беткән ул малай...

— Ничек беткән?

— Башта аракы белән мавыкты. Инде наркоманиягә авышкан.

— Менә шул Юнысыч, үзенең иске коверын китертеп, әлеге мәктәпкә дип бирелгән яңаны өенә кайтарткан иде. Нәрсә шаккатып карап торасыз, ышанмыйсыз мәллә? Ник дәшмисең, Әхмәт? Шабашкада эшләгән чагыгызда Фәрит белән икегез төяп озаткансыз бит.

— Элек район җитәкчеләре ярлы булган, димәк, — диде Әхмәт, көлемсерәп. — Ятимнәр өлешеннән курыкмагач, эшләре хөрт булган инде мескеннәрнең.

— Әйе, без аны илтеп, җәеп тә кайттык... Табак йөзле, ниндидер үзгә як сөйләшле хатынының тө-сен-бизәген ошатмыйча мыжгып маташуы, ә Фаил Юнысычның, кайткан нәрсәгә риза бул, анаңны, дип сүгенгәне истә калган, — дип куйды Фәрит.

— Һәрнәрсәне динамикада, үсештә карарга кирәк, — дип, тагын акыл сатарга кереште Зиннәт. — Келәм алып кайту ул — этап. Ә бүгенге җитәкче балалар йортына акчаны үз кесәсеннән чыгарып тоттыра икән, димәк, азлап урлашу чоры узган, димәк, керем күпкә арткан...

— Главага чүп инде ул җиде мең...

— Минем өч айлык эш хакы, — дип ыңгырашып куйды Фәрит. — Туктагыз, югыйсә, валлаһи, шул җүләрләр бәхетеннән көнләштерә башлыйсыз.

— Елына җиде миллион акча сарыф итә икән ул мәктәп, — дип, утка крәчин өстәвемне дәвам итәм, Фәритне тагын да ирештерүдән тәм таба башлап.

— Дуракларга һәрвакыт мач, — диде Зиннәт. — Талантларны аяк астына салып таптыйлар, ә дуракларны күтәрәләр... Күпме язып бер китап чыгарырга җай юк, анасын сатыйм.

— Язган нәрсәләрең булса, мин сиңа китап чыгарырга булыша алам, — диде Әхмәт.

— Ә яхшылыгыңа ничек җавап бирермен? Аннары бит минем бар язганнар сезнең братка үч, ачу һәм нәфрәт белән сугарылган.

— Анысы өчен борчылма, хәзер күпләр китап укымый, тем более безнең брат...

— Хактан да...

— Кем әйтмешли, җырлап яши торган заман килде. Зиннәт бәрәңге кабыгы астыннан бер газета тартып чыгарды.

— Җыр дигәннән, менә монда атаклы җырчы Гыйбад Яманаевның юбилее хакында язганнар, тужы үзенә күрә кәрүл, поддыннныйлары, фанат-фанаткалары бихисап, имеш. Күрче, кемнәр белән кочаклаша.

— Яманаевның дуслар турында бик шәп җыры бар, әйдә, Заһит, ал гармуныңны, бер әйттерик әле шуны.

— Өченче ел безнең авыл болынында да концерт куеп китте ул Яманаев, — диде Фәрит.

— Акчасын кем түләде микән, Гыйбад юк-бар хакка йөрми хәзер, — дип кызыксынды Әхмәт. — Юк-юк та ике-өч йөз меңне каергандыр әле.

— Минем хуҗа, Мөбарәк түләде, — диде Заһит. — Халыкка игелек концерты күрсәтеп, ниндидер налогтан котылып була иде ул заманда. «КамАЗ» белән Т-150 тракторларына бик күп запчасть әйләндердек. Мин ташыйм, Мөбарәк урнаштыра, зарлана алмыйм, начар түләмәде. Гыйбад Яманаев бәләкәй автобус белән байтак аппаратура төяп килгән иде. Халык яратты моны, җыры саен котырып кул чапты. Ә бермәлне чираттагы алкышлардан соң музыкантлары белән киңәшкәндә, микрофонын өзәргә оныттымы, юри шулай иттеме:

— Бу сарыкларга тагын нәрсә җырлыйсы микән инде? — дип сөйләнгәне дә ишетелде.

— Тотып ярмадыларммы соң шул сүзе өчен?

— Яра ди сиңа. Исе дә китмәде халыкның, тилерә-тилерә алкышлавын белде, — диде Заһит һәм кулын алга таба селтәп дәвам итте: — Ә концерттан соң боларны колхоз ашханәсендә сыйладылар. Шуннан Яманаев артист хатынын, музыкантларын, аппаратларын килгән машинасына төяп озатты да, үзе колхоз кунакханәсенә кереп батты. Мөбарәк әйтә, моны сиңа «Нива»ң белән илтеп куярга туры килер, бер ярты сәгать ял итәм, диде, ди. Көтәм. Арткы утыргычка ике җырчы кызы да кереп утырды. Көтәбез... Баксаң, концерт барышында безнең якның бер сылу хатыны моңа үзенең мәхәббәтен белдергән, шуны кабул итә булып чыкты, субакы.

— Кем ул, теге уткүз фелшер түгелдер бит?

— Юк, егетләр, анысын ук сорамагыз, ирдәге нәмәрсәкәй, гаиләсе таркалырга мөмкин, бәласеннән башаяк. Яшерен-батырын түгел, үземнең дә күз төшеп йөри әле ул кабахәтурага... Ну дурак инде хатын-кыз. Минем белән чагыштырганда, тәләкә бит инде теге, ә шуңа капланалар. Любое шуңа каплана. Гел юлда йөргән артист халкы әллә ниткән чир белән дә бүләкләп китәргә мужыт югыйсә, уй юк хатын-кызда...

— Уй кирәк түгел аңа...

— Йә, йә, шуннан.

— Ну, шуннан башта гостиница ишегеннән шул түти чыгып сызды, аннары бу күренде. Арткы ишектән кереп, җырчы кызлар арасына утырды да, минем җилкәгә кагылып:

— Трогай, братан! — ди.

Барабыз. Күпмедер юл үткән идек, артта хәрәкәт, ыгы-зыгы китте. Көзгегә карасам, күзләр маңгайга менде, чүт кырыйга төшеп китмәдем. Теге «йолдыз» димме, дуңгыз димме, чалбар каешын ычкындырган, кызларның чәчләреннән урап тоткан. «Сезнең ише «лә-лә» дип торучылар бер сызгырсам унау җыела, мин сезгә зрәгә генә акча түлим, что ли, эшегезне белегез», — дип, әле берсен аска иелдерә, әле икенчесен. Мине дә онытмый:

— Син, братан, алдыңа кара, йә мәтәлеп төшеп китәрсең, — ди.

— Исең киткән икән, — дип кеткелдәп көлде Әхмәт. — Хәзер модасы шул бит аның.

— Аулакта теләсә нишләсеннәр, анда минем эшем юк. Бу бит, төрмәдәге сымак, төпкә батыру, опускать итү белән ләззәтләнә. Кеше күз алдында. Үземнең олы кыз җырчы булам дип хыялланып йөри иде, кайткач, аны туздырып аттым.

Заһит, йодрыгын төйнәп, кулын алга сузды:

— Менә сиңа, — мәйтәм, — артист булу! Менә моннан нәрсә исе килә?!

Зиннәт янә черт итеп төкереп куйды:

— Шул ук кәсафәт, тулы түгеллек комплексы, — диде шагыйрь. — Әнә ничек үзен расларга керешкән, тфү, сәхнә аферисты.

— Егетләр, бу шактый мөхтәрәм затлар арасында да йөри. Ул бит аларның абруена тап төшерергә мужыт.

— Бу үзе шул «абруйлыларны» кабатлый. Һәм надан буларак арттырып җибәрә. Бар да бер камырдан, һәммәсе дә җарияләр тота. Паханлыкның сәхнәне дә яулавы кызганыч, әлбәттә. Нишлисең, хәзерге шартларда бу котылгысыз...

— Ә бәлкем, Гыйбад яшьлегендә утырып чыккандыр, шуңа пахан буласы килеп калгандыр?

— Алай гына түгел әле ул, егетләр, ташлагыз шул гадәтегезне, — дип, янә сүзгә кушылды моңарчы телен тешләп торган Фәрит. — Нәрсә соң сез һәркемне пычратасыз? Гыйбад — менә дигән җырчы. Зур исемнәр, бүләкләр алды, аны түрәләр генә түгел, һәркайда олылыйлар, шул исәптән сезнең братлар да!

— Кем инде ул минем брат андый?

— Үзебезнең егет дип язып чыкты әнә Аптул Нәҗибин үзе!

— Кем дип белдең соң син ул Аптулны?

— Дур язучы дип, шагыйрь дип.

— Аптул Хөснетдиныч гомере буе, хакыйкать эзләүче маскасын киеп, хакимиятнең иң тугры ялчысы буларак иҗат итте, беркемне дә тикмәгә депутатлыкта йөртмиләр, агай-эне. Миңа калса, аның да теге җырчы кызлардан аермасы юк. Ул фахишәлекнең үзгә төрендә хезмәт күрсәтә. Ә беләсезме, миңа шул Хөснетдинычның, аны үзе юкта шулай Хөсеттиныч дип «зурлыйлар», Мәһди Мәхмүтовка үпкәләп язган хатын укырга туры килде...

— Ә ничек укыдың син аны?

— Ул минем әнигә туган тиешле... Төркиягә Татарстаннан премьер катнашындагы делегациядә Мәхмүт абый барган иде бит, ә Аптулны ияртмәгәннәр, һәм бу шуңа үпкәләгән. Ни генә язып бетермәгән абыйга, чәчләрең үрә торырлык...

— Ярый, аны хөсетле, диик. Ә үзебез кем? Ник бер дә шул сорауны бирмибез үз-үзебезгә?

— Егетләр, даваегыз җырлыйк, Гыйбадныкыннан башка җырлар да күп. Әйдәгез, Таһир Якупов башкарган «Карачтау авылы җыры»н тырышып карыйк йә «Олы юлның тузаны»н. Тарт инде

гармуныңның колагын, Заһит дус, күпме гайбәт сатып утырырга мөмкин! Гаеп бит үзебездә дә тау кадәрдер, ә кемнәрдер безне тикшереп утырадыр әле. Бездән пүчтәгрәкләр...

«Хан аракысы» белән тамак чылатып алгач, ниһаять, җырга да чират тиде, таллыкларга күмелгән инеш яры буйлап болынлыкка җыр таралды:

Олы юлның тузанын
Үзем күрдем тузганын...

Җыр, болынны тутырып, авылга ук барып иреште. Моңлы җыр, вак сүзләр, гайбәткә уралган җаннарны сафландырып-тазартып, югарыга, биеккә, чисталыкка, пакьлеккә җилкендерде...

## Сине сөйдем, гүзәлем...

Габделнур электән «тегеләйрәк» чутында йөрде. Янәсе, җиде классны «валлаһи» өчлеләргә тәмамлаган, имеш, армиягә алмаганнар... Укытучы әнием сөйләгәне истә: «Бездә башлангыч мәктәп кенә иде, җидееллык белем учагы — күрше авылда. Дүртне тәмамлаучыларга шунда барып, язмача имтихан тапшырасы».

Имтихан тәмам була, балалар җәяүләп авылга кайтып китәләр, ә әни, нәтиҗәне белер өчен, ахирәт дустында куна кала. Шул ханым, кичен мәктәпләрен урап кайткач:

— Котлыйм, Мәрфуга, бик көчле математигың бар икән, Хәйруллин Габделнур, диделәр, аңа бишле, калган укучыларың өчлегә, дүртлегә язганнар, икелеләр юк, бар да күчә, — дип сөенче ала.

— Ике парта аша үрелеп, кемнәндер күчергәнен абайлаган идем аны, тәки очына чыккан, — дип кеткелдәп көлә әни.

Габделнурның очына ат кылы тагылган, каештан телеп җидегә үргән, сөяктәй шома саплы әкәмәт озын чыбыркысына күзе кызмаган малай юк иде. Баш очыңнан болгап, шуны бер селкесәң, бөтен авыл тәрәзәләре зың итә иде чөнки...

Егет чиста-пөхтә киенеп йөри, әнисенең кадерле улы, тамагы тук, җиде сыйныфны очлап чыккач, менә дигән эшле булды: үлән күренгәннән кара көзгәчә җырлап көтү көтә, ә аннары, берәр итекчегә ялланып, янә җырлый-җырлый йон тетешә.

Аның «Барыня» көенә:

Сездә кемнәр киндер суга,
Хәбиб белән Афзал, —

дип өзми-куймый шыңшыганнарын хәтерләүчеләр бардыр әле.

Кыскасы, егет үз тормышыннан канәгать, шуңадыр йөзе гел көләч, гел нурлы моның. Әмма көннәр гел аяз гына тормый шул. Бермәлне әнисе Мәмдуха апа хакында «Врачлар рак тапкан, көннәре санаулы икән» дигән шомлы хәбәр таралды. Озак тормады Мәмдуха апа, җеназасын күтәрешергә бөтен авыл чыкты, күрше-тирәдән дә озатырга дип килүчеләр күренгән. Әмма ул, үз хәлен үзе белеп, үләренә бер ай кала күрше авылга барырга һәм анда яшьлектә араларында нидер булган кордашы Җамали агай белән сөйләшергә вакыт тапкан:

— Бир минем улыма кызыңны!— дип инәлгән.

Һәм янәшә-тирәдә чибәрлеге белән дан тоткан Гүзәлия безнең авылга килен булып төште... Кыз башта карышып маташкан, әмма Җамай коры, кансыз кеше икән: «Тыңламасаң, бәрдем-үтердем», — дип кырт кискән, һәм, әтисе сүзен сүз итеп, Гүзәлия сынган, ризалашкан. Битләренә алма алсулыгы йөгергән, җиңел сөякле, һәркем белән тиз аралашып китүчән ягымлы бу баланы барча авылдашлар үз итте. Җәлләделәр, «Габделнурга әрәм бу» диделәр, «Бәхете бар икән Габдүшнең» дип тел шартлаттылар.

Беркөнне Габделнур безгә килде дә:

— Безнең Гүзәлия китап укый да китап укый, Мәрфуга апа, китап бир әле? — дип, әнидән бер кочак «Совет әдәбияты» журналы алып чыгып китте.

Күтәренеп кайтканда, моңа ат караучы Назыйм абый очраган. Аны «утырып» та кайткан дип сөйлиләр, имеш ки, кешегә бәйләнә торган гадәтен шуннан алып кайткан.

— Китап кирәк түгел аңа!— дип сүккән Назыйм абый Габделнурны. — Болай йөрсәң, тәки авылны матур киленсез калдырасың, — дип орышкан. Аннары, Габдинең ипи шүрлегенә менеп төшеп, нишләргә кирәклеген бәйнә-бәйнә аңлатканын ишетеп, тыңлап торучылар булган...

Назыйм абый яшьлегендә үзе дә әздән генә чибәр кызга өйләнми калган. Күрше авылдагы мәгъшукасына кызыгучылар тагын булган, күрәсең, моңа сугышкаларга да туры килгән. Әмма берсендә, күбәүләп ябырылгач, кесәсеннән пычак чыгарган. Егетне салкын корал йөрткәне өчен кулга алганнар. Елын тутырып кайтса, чибәркәе кияүгә киткән. Шуннан моңа ямьсез кызга өйләнүдән гайре чара калмаган. Хәер, өтермәдән кайткан кешегә ярамаган тагын...

Атна азагында Гүзәлиянең китеп баруы мәгълүм булды. Бу хәйләкәр кызый төн дә үзенең авылда калган сөйгәне белән очрашу җаен тапкан. Габделнур караватка яткач, мин бераз укыйм әле дип, китапка багына да, теге йокыга китүгә, чишмә буена чыгып тая икән. Ә Габделнур йокыга каты, көн буе саф һавада көтү көтү уен эш түгел, бер мәмрәсәң, ничек айнымак кирәк ди йокы исереклегеннән.

Аның караву бригадир Сәләхинең йокысы сак. Тизрәк таң атуын көтеп җиткерә алмаган төннәрнең берсендә бу, тәмәке кабызып, урамга чыга һәм күрә: чиләк-көянтә күтәргән бер хатын чишмә ягына ашыга... Ә чишмәгә кукуруз басуы терәлеп тора.

«Әһә, — дип уйлый бригадир, — бу вакытта суга бармыйлар, бу чәкән ботамакчы!» Шыпырт кына артыннан тагыла. Әлеге матавыкның ни белән тәмамлануын төгәл белүче юк, чөнки бригадирны иртән сөйләштереп булмый, ә кичкә таба теле ачыла да аңларлык булмый... Шунысы бәхәссез: куркыткан ул асыл кошларны...

Бәхетеңне керпе үпсә,
Керерсең төрмәләргә;
Чапкан ристаннар шикелле,
Бет йөрер бөрмәләрдә, —

дигән җыру өйрәткән иде безгә кайчандыр Назыйм абзыкай. Тәкъдирдә «өлешеңә чибәр хатын» дип язылган булса да, тайпылулар юк икән! Әлеге дә баягы, һаман да шул күрше авылда инде, яшь бер кыз сатучы булып эшкә урнаша. Райондагы склад мөдире моны, тәҗрибәсезлегеннән файдаланып, төп башына утырта, накладноеның буш калган урынына өстәп нәрсәләрдер яза. Һәм ревизия вакытында туташыбызның «өстеннән чыга». Растрата ясаган өчен төрмәгә үк утыртасы булганнар, имеш ки, сельпо рәисе аралаган, дип сөйләделәр. Аралавын аралаган, әмма бураznаны да бозган карт алаша, кызыкай йөккә узган. Ул заманда андый эшләр зур гаеп, сафлыгын җуйган кызга өйләнү хурлык санала иде бит. Кемнәрдер моның ата-анасына корсагы борынына җитә башлаган кызларын Габделнурга урнаштырырга киңәш иткән.

Һәм көтүчебез янә хатынлы булды. Бусы китәргә дип тә килмәгән икән. Бер-бер артлы туп кебек ике малай, аннары алмадай ике кыз алып кайтты. Үзен һич тә дүрт бала анасы димәссең, караплар торышлы, бер кашык су белән йотарлык: чибәр дә, сылу да, уңган да... Җитмәсә, «Габделнур» дип өзелеп тора.

Габделнурның бәхетен күпсенүче табылган. Чыбыркысын өстерәп, озын-озын атлап урамнан кайтып барганда, һаман шул Назыйм, моны туктатып, көтү каршыларга чыккан хатыннар алдында:

— Синең беренче малаең үзеңнеке түгел инде, калган өчесе кемнәрдән соң?— дип ыржайган.

— Алары супсунный (собственный була инде), үземнеке!— дип җавап биргән Габделнур, елмаеп-балкып.

Мәҗлесләрдә «җырла» дип кыстасалар, Габделнур әллә ни ялындырмый. Аның тавыш бераз карлыкканрак, әмма шактый моңлы:

Яшьлегем чәчәк атканда,
Сине сөйдем, эһеһем...

«Эһеһем» дип кенә җырлый Габделнур, беркайчан да «гүзәлем» дип әйтми. Үткәндәгене онытмавын авылдашларына сиздерергә теләмәүдәнме бу, хатыныннан уңайсызланамы, белмәссең?.. «Эһеһем»не әйткәч, тирән итеп, әллә ниткән ыңгырашулы сулыш ала һәм каядыр кырыйга, читкә, еракка карап дәвам итә:

Тик бер үзем генә белдем
Үзәгем өзелгәнен...

## Эчтәлек

**Шигырьләр**


Бүре
Ак килешә
«Инде менә күпме уйладым...»
Ак болытлар йөзеп йөрер күктә...
Империя
Безне көтәләр...
Кырым
Әни
Беренче кар
Халәт фасыллары
Солтанәхмәт
«Күтәрелеп карадың да...»
«Китеп барган чак та булды...»
Парадокс
Туташ
Ишек шакыдылар...
Урман
«Җәйне — яшәү, кышны тыну, диләр...»
«Юк, яратмый идем, күрсәм җилдә...»
«Кайчакларда сагыш ачыттыра...»
«Беркем хәтерләми икебезнең...»
Майтап җиңгинең Халит абзый колагына ирештергәннәре
Төш
«Имеш, матур чәчәк атсын өчен...»
«Җитәкчене шуннан таныйм...»
«Аргамактан туа тулпар...»
СССР тарихы
Туган тел
Һәйкәл
Җирсү
Зыялыларыбыз
Бу безнең ил түгел...
Исе китәр иде исәрнең
Мишә ярыннан йөгердек...
Фоторәсем
Юл чатында
Хирург монологы
Ирек мәйданы. 1991
«Ачыгыз авызыгызны...»
Саба
Мөһаҗир җыры
Кәҗә монологы
Сәхнәләрдә «йолдыз», һай, ничәдер?
Әдәбият дәресендә әңгәмә
Китапханәдә
«Балта суга төшү — кайгы...»
«Түрә булсам, мин җикерәсе...»
«Кабинет зур, машина шәп...»
«Күтәренке күлмәк, ачык кендек...»
«Кеше хакын басып калучы...»
«Яшьлегем, кайт, кайт кире», — дип...
«Ерак йөрми бездән һәлакәт тә...»
Йолдыз сүзе
Татар-башкорт көрәше
Көрәш
Милләтеңә тидермә тел...
Еллар узгач...
«Хәерчеләр күңелләрен...»

«Эшче һәм игенче, сезнең базар...»
«Күлмәгеңне кычытканнан тукыт...»
Пушкин
Түрә фикере
«Бәхет — әкияттәге ат ул...»
«Үлән гашыйк тормышка...»
«Тузлы кабык җыештырып йөри...»
«Түрә — гүя үрдәк...»
«Сүз эзләп кесәгә керми...»
«Тегермән җил уңаена түгел...»
Хатын алдым
Диңгез кебек
Бармы җаныгыз?
Бәгъзеләребез...
Трамвайда төш
«Ак болытларга карыйм да...»
«Чын ир заты кайтып керсә — тансык кунак...»
«Мөхәррир тәфтишли һәр язганны...»
Кабат кайтмый икән...

**Хикәяләр**

Кирт
Олы юлның тузаны
Сине сөйдем, гүзәлем...

Литературно-художественное издание

**Зарипов** Рустам Заетович

Ветерок апельсина

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Зарипов** Рөстәм Зәет улы

Әфлисун җиле

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Б.В.Муфахаров*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.09.2008.
Форматы 70×90 $^{1/32}$. Шартлы басма табагы 3,51.
Шартлы буяу-оттиск 3,80. Нәшер-хисап табагы 3,13.
Тиражы 1000 д. Заказ Т-1284.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.